К.С. Фәтхуллова, А.Ш. Юсупова, Э.Н. Денмөхәммәтова

# ТАТАРЧА СӨЙЛӘШӘБЕЗ, УКЫЙБЫЗ, ЯЗАБЫЗ

**Рус телендә сөйләшүчеләр өчен татар теле дәреслеге**

***Башлангыч дәрәҗә***

# ГОВОРИМ, ЧИТАЕМ, ПИШЕМ ПО-ТАТАРСКИ

**Учебное пособие по татарскому языку для русскоговорящих**

***Начальный уровень***

Казан

2012

УДК 811.512.145 : 811.161.1
ББК 81.2Тат : 81.2Р-4
Ф96

Рецензентлар:

**З.Н. Кириллова** – филология фәннәре кандидаты;

**Г.Ә. Нәбиуллина** – филология фәннәре кандидаты

**Фәтхуллова К.С. һ.б.**

Ф96 Татарча сөйләшәбез, укыйбыз, язабыз. / К.С.Фәтхуллова, А.Ш.Юсупова, Э.Н.Денмөхәммәтова. — Казан: Татарстан Республикасы «ХӘТЕР» нәшрияты, 2012. — 184 б. : ил.
ISBN 978-5-94113-402-1

Дәреслек үз эченә 18 теманы ала. Һәр тема аралашу ситуацияләренә бәйле тел һәм сөйләм берәмлекләрен гамәли үзләштерүгә кайтып кала. Дәреслекне укытучы җитәкчелегендә татар телен өйрәнү өчен дә, мөстәкыйль рәвештә үзләштерү өчен дә кулланып була. Дәреслек татар теле белән кызыксынучыларга һәм өйрәнүчеләргә тәкъдим ителә.

Учебное пособие включает в себя 18 тем. Каждая тема способствует усвоению речевых единиц,связанных с ситуацией общения. Пособие предназначено для изучения татарского языка как под руководством преподавателя, так и самостоятельно.

УДК 811.512.145 : 811.161.1
ББК 81.2Тат : 81.2Р-4

ISBN 978-5-94113-402-1

© Фәтхуллова К.С., Юсупова А.Ш., Денмөхәммәтова Э.Н., 2012
© Татарстан Республикасы «ХӘТЕР» нәшрияты, 2012

**Кадерле дуслар!**

Сез татар телен өйрәнә башлыйсыз. Дәресләрдә сез татарча сөйләшерсез һәм аралашырсыз. Дәреслек татар телен шәхесара һәм мәдәниятара аралашу чарасы буларак үзләштерү максатыннан төзелде һәм моның өчен кирәкле шартлар тудыра. Дәреслектә төрле диалоглар, кечкенә текстлар һәм шигырьләр, коммуникатив биремнәр, рәсемнәр һәм фотолар күп. Алар сезгә татар телен гамәли үзләштерергә ярдәм итәр.

**Татар теле дәресләренә рәхим итегез!**

**Авторлар**

***

**Дорогие друзья!**

Вы начинаете изучать татарский язык. На уроках вы будете говорить и общаться по-татарски. Учебник разработан с целью усвоения татарского языка как средства межличностного и межкультурного общения и создаёт для этого необходимые условия. В учебнике много разных диалогов, небольших текстов и стихотворений, коммуникативных заданий, картинок и фотографий. Они помогут вам практически усвоить татарский язык.

**Добро пожаловать на уроки татарского языка!**

**Авторы**

**Эчтәлек.** Содержание

1. **Танышу.** Знакомство........................................ 5

2. **Мин һәм минем гаиләм**. Я и моя семья........................................ 17

3. **Мин һәм минем дусларым**. Я и мои друзья........................................ 27

4. **Һөнәрләр. Уку һәм эш**. Профессии. Учёба и работа........................................ 35

5. **Телләр белү.** Знание языков........................................ 45

6. **Йорт. Фатир.** Дом. Квартира........................................ 54

7. **Һава торышы. Көн. Атна. Ай. Ел**. Погода. День. Неделя. Месяц. Год. 63

8. **Ел фасыллары.** Времена года........................................ 71

9. **Бәйрәмнәр.** Праздники........................................ 78

10. **Көндәлек режим**. Режим дня........................................ 87

11. **Сәламәтлек**. Здоровье........................................ 94

12. **Спорт уеннары**. Спортивные игры........................................ 102

13. **Минем буш вакытым**. Моё свободное время........................................ 111

14. **Кибеттә.** В магазине........................................ 119

15. **Шәһәрдә һәм авылда**. В городе и в деревне........................................ 129

16. **Кунаклар каршылау**. **Татар милли ашлары.** Встреча гостей. Татарские национальные блюда........................................ 138

17. **Табигатьтә.** На природе........................................ 146

18. **Сәяхәт итү.** Путешествия........................................ 155

**Гомуми тест.** Общий тест........................................ 163

**Кушымта.** Приложение........................................ 170



## **ТАНЫШУ.** ЗНАКОМСТВО

**1. Тыңлагыз һәм укыгыз. Үзегезнең исемегезне әйтегез.** Прослушайте и прочитайте. Назовите своё имя.

**Сез кем?** Кто вы? **Син кем?** Кто ты?

Мин – Азат. Мин – Булат. Мин – Фәрит. Мин – Рәшит.

Мин – Әлфия. Мин – Лилия. Мин – Алсу. Мин – Әминә.

**мин – я**

**2. Диалогны тыңлагыз һәм укыгыз.** Прослушайте диалог и прочитайте.

**— Гафу итегез, Сез кем?**

**— Мин – Алсу. Ә Сез кем?**

**— Мин – Әминә.**

**гафу итегез – извините**

3. **Тыңлагыз һәм кабатлагыз.** Прослушайте и повторите.

**Бу кем?** Кто это?



Бу – Азат.



Бу – Алсу.

**ханым – госпожа**
**әфәнде – господин**
**туташ – девушка**



Бу – Әминә ханым.



Бу – Әнәс әфәнде.



Бу – Зилә туташ.

4. **Диалогны тыңлагыз һәм укыгыз.** Прослушайте диалог и прочитайте.

— Гафу итегез, бу кем?

— Бу – Әнәс әфәнде.

— Ә бу кем?

— Бу – А́лсу.

5. **Үрнәк буенча үзегез һәм дустыгыз турында әйтегез.** Скажите о себе и о друге (подруге) по образцу.

*Үрнәк:* Мин – ... ..   Ә бу – ... ..

6. **Тыңлагыз һәм укыгыз. Татарча исәнләшергә һәм саубуллашырга өйрәнегез.** Прослушайте и прочитайте. Научитесь здороваться и прощаться по-татарски.



— Исәнме, А́зат!

— Исәнме, Булат!

**Исәнме! – Здравствуй!**



— Исәнме, Иркә!

— Сәлам, Мәликә!

**Сәлам! – Привет!**



— Сау бул, Марат!

— Исән бул, Ринат!

**Сау бул! – До свидания!**



— Сау бул, Лилия!

— Исән бул, Әлфия!



— Исәнмесез, Әминә апа!

— Исәнме, Алсу!

**Исәнмесез! — Здравствуйте!**



— Исәнмесез, Алсу ханым!

— Исәнмесез, Әмир әфәнде!



— Сау булыгыз, Фәрит абый!

— Сау бул, Булат!



— Сау булыгыз, Фәрит әфәнде!

— Сау булыгыз, Булат әфәнде!

7. **Җөмләләрне укыгыз.** Прочитайте предложения.

Таныш булыйк, мин – Әлфия.

Син кем? Мин – Азат.

Ә бу кем? Бу – Булат.

Исәнме, Әнәс! Исәнме, Әнисә!

Исәнмесез, Әминә апа! Исәнмесез, Фәрит абый!

Исәнмесез, Рөстәм әфәнде! Исәнмесез, Зилә ханым!

Сәлам, Гүзәл! Сәлам, Рузәл!

Сау бул, Азат! Сау бул, Булат!

Сау булыгыз, Әминә апа! Сау булыгыз, Фәрит абый!

Сау булыгыз, Илдар әфәнде! Сау булыгыз, Әнисә ханым!

**Сау булыгыз! — До свидания!**

**Таныш булыйк! — Давайте познакомимся!**

**апа – тётя**
**абый – дядя**

8. Тыңлагыз һәм укыгыз. Сорауларга җавап бирергә өйрәнегез. Прослушайте и прочитайте. Научитесь отвечать на вопросы.



— Син Алмазмы?

— Әйе. Мин – Алмаз.



— Син Әнисәме?

— Әйе. Мин – Әнисә.

әйе – да



— Син Булатмы?

— Юк.

юк – нет



— Син Гөлназмы?

— Юк. Мин Гөлназ түгел, мин – Эльвира.

түгел – не

* * *

— Сез Әминә апамы?

— Әйе, мин – Әминә апа.

* * *

— Сез Зилә ханыммы?

— Әйе, мин – Зилә ханым.

* * *

— Сез Рүзәл әфәндеме?

— Юк. Мин Рүзәл әфәнде түгел.

**Истә калдырыгыз!** Запомните!

**-мы/-ме – сорау кисәкчәләре** (вопросительные частицы)

**Алсумы? Әминәме?** Алсу? Амина?

**9. Үрнәк буенча сораулар бирегез.** Задайте вопросы по образцу.

*Үрнәк:* Син Ринат**мы**?

Сез Фәрит абый**мы**?

Сез Әминә апа**мы**?

Сез Рәшидә ханым**мы**?

А О У Ы Э

Син Мәлика**ме**?

Сез Ирек**ме**?

Сез Марат әфәнде**ме**?

Ә Ө Ү И

**10. Сорауларга җавап бирегез.** Ответьте на вопросы.

Бу Маратмы? **Әйе**

Бу Алсумы? **Юк**

Бу Әминә апамы? **Әйе**

Бу Фәрит абыймы? **Юк**

**11. Диалогларны тыңлагыз һәм укыгыз.** Прослушайте диалоги и прочитайте.




— Исәнме, Алсу!
— Сәлам, Мәликә!
— Алсу, бу кем?
— Бу – Камилә.
— Ә бу кем?
— Ә бу – Җәмилә.




— Исәнме, Азат!
— Сәлам, Самат!
— Азат, бу кем?
— Бу – Булат.
— Ә бу кем?
— Ә бу – Марат.

**12. Рәсемнәргә карагыз һәм диалог төзегез.** Посмотрите на рисунки и составьте диалог.



**13. Тыңлагыз һәм укыгыз.** Прослушайте и прочитайте.

**Син кайдан?** Откуда ты? **Сез кайдан?** Откуда Вы?

Алсу Мәскәүдән.

**мин – я**

**син – ты**

Мансур Самарадан.

**ул – он, она**

Мин Ташкенттан.

**без – мы**

Ул Әлмәттән.

**сез – вы**

Алар Төмәннән.

**алар – они**

Без Казаннан.

**Истә калдырыгыз!** Запомните!
*-дан/-дән, -тан/-тән, -нан/-нән* – **чыгыш килеше кушымчалары** (аффиксы исходного падежа)
**Кайдан?** Откуда?
Самара**дан**, Мәскәү**дән**
Ташкент**тан**, Әлмәт**тән**
Казан**нан**, Төмән**нән**

**14. Сорауларга җавап бирегез.** Ответьте на вопросы.

Син кайдан?

**м**

**н**

Бу туташ кайдан?

**ң**

Алар кайдан?

**Казаннан**

**Мәскәүдән**

**Самарадан**

**15. Диалогларны укыгыз һәм үрнәк буенча төзегез.** Прочитайте диалоги и составьте по образцу.

*Балалар җәйге лагерьда танышалар. Дети знакомятся в летнем лагере.*



— Исәнме!

— Сәлам!

— Таныш булыйк, син кем?

— Мин – Артур. Ә син кем?

— Мин – Мансур.

— Мин бик шат, Мансур!

— Мин дә бик шат, Артур.

— Мансур, син кайдан?

— Мин Казаннан. Ә син кайдан?

— Ә мин Самарадан.

— Исәнме, Кәрим!

— Сәлам, Әминә!

— Кәрим, бу кем?

— Бу – Галия.

— Ул кайдан?

— Галия Уфадан.

**16. Дустыгызның фотосын күрсәтегез һәм аның турында әйтегез.** Покажите фотографию друга (подруги) и скажите, как его (её) зовут, откуда он (она).

*Бу – ... . Ул ...*

**Истә калдырыгыз!** Запомните!

***-лар/-ләр, -нар/-нәр* – күплек сан кушымчалары** (аффиксы множественного числа)

кыз – кыз**лар** (девочки, девушки)

малай – малай**лар** (мальчики)

кеше – кеше**ләр** (люди)

әфәнде – әфәнде**ләр** (господа)

ханы**м** – ханым**нар** (дамы)

бәйрә**м** – бәйрәм**нәр** (праздники)

**17. Сорауларга җавап бирегез.** Ответьте на вопросы.

Бу кызлар кайдан?

Бу малайлар кайдан?

Бу ханымнар кайдан?

Бу әфәнделәр кайдан?

Бу туристлар кайдан?

Бу студентлар кайдан?

Бу балалар кайдан?

**Саратовтан**

**Пермьнән**

**Яр Чаллыдан**

**Бөгелмәдән**

**Санкт-Петербургтан**

**Ульяновскидан**

**Төмәннән**

**Истә калдырыгыз!** Запомните!

| | | |
|---|---|---|
| Саратов**тан** | Псков**тан** | Германия**дән** |
| Санкт-Петербург**тан** | Оренбург**тан** | Төркия**дән** |
| Ульяновск**идан** | Красноярск**идан** | Америка**дан** |

**18. Шигырьдән өзекне өйрәнегез.** Выучите отрывок из стихотворения.

… — Исәнме, Гүзәл!
Исәнме, Рүзәл!
Исәнме, Мәрьям!
Исәнме, Галләм!
Сезгә, дусларым,
Иртәнге сәлам!
— Исәнме, Иркә!
— Сәлам, Мәликә!
Хәерле иртә!
Хәерле иртә!

*Хәләф Гардановтан*

**Хәерле иртә! – Доброе утро!**

**Хәерле көн! – Добрый день!**

**Хәерле кич! – Добрый вечер!**

**Хәерле юл! – Доброго пути!**

**19. Дөрес әйтегез.** Скажите правильно.

а – [а°] – Алсу, Азат
[а] – Антон, Анна

ә – [ә] – Әминә, Әнәс

**20. Дөрес языгыз.** Напишите правильно.

*А а* ______________________________

*Ә ә* ______________________________

☑ **ҮЗ-ҮЗЕГЕЗНЕ ТИКШЕРЕГЕЗ!** ПРОВЕРЬТЕ СЕБЯ!

1. **Дөрес җавапны табыгыз.** Найдите правильный ответ.

Ул Казан...
1) -дан 2) -тан 3) -нан

Алар Самара...
1) -дан 2) -дән 3) -нан

Без Мәскәү...
1) - дан 2) -дән 3) -нән

Мин Пермь...
1) -нан 2) -нән 3) -тән

Бу ханым Саратов...
1) -тан 2) -дан 3) -тән

Бу әфәнде Яр Чаллы...
1) -дән 2) -нан 3) -дан

Бу апа Бөгелмә...
1) -дан 2) -тан 3) -дән

Бу кеше... Америкадан.
1) -лар 2) -нәр 3) -ләр

Бу ханым... Уфадан.
1) -лар 2) -нар 3) -нәр

Бу бала... Ташкенттан.
1) -лар 2) -нар 3) -ләр

2. **Дөрес тәрҗемәне табыгыз.** Найдите правильный перевод.

**Без**
1) они 2) я 3) мы

**Сәлам**
1) здравствуй 2) привет 3) доброе утро

**Хәерле кич**

1) доброе утро 2) добрый день 3) добрый вечер

**Түгел**

1) нет 2) не 3) да

**Әфәнде**

1) девушка 2) господин 3) госпожа

**Кешеләр**

1) дамы 2) мальчики 3) люди

**3. Коммуникатив биремнәр.** Коммуникативные задания.

1) Поздоровайтесь с другом (подругой) по-татарски.
2) Спросите у знакомого, откуда он.
3) Скажите, что это Алсу, она из Казани.
4) Скажите, что это Алмаз, он из Москвы.
5) Скажите, что эти люди из Пензы.
6) Скажите, что эти туристы из Америки.
7) Извинитесь и спросите у девушек, откуда они.
8) Попрощайтесь с другом (подругой) по-татарски.
9) Попрощайтесь с учителем татарского языка.
10) Пожелайте другу (подруге) доброго пути.



## МИН ҺӘМ МИНЕМ ГАИЛӘМ. Я И МОЯ СЕМЬЯ

**1. Тыңлагыз һәм укыгыз.** Прослушайте и прочитайте.

**Бу кем?** Кто это?



Бу – әни.



Бу – әти.



Бу – әби (дәү әни).



Бу – бабай (дәү әти).

2. Рәсемнәргә карагыз һәм сорауларга җавап бирегез. Посмотрите на рисунки и ответьте на вопросы.

Бу кем?



3. «Бармаклар» шигырен тыңлагыз һәм өйрәнегез. Прослушайте и выучите стихотворение «Пальчики».

Бу бармак – бабай,
Бу бармак – әби,
Бу бармак – әти,
Бу бармак – әни.
Бу бармак – нәни бәби,
Аның исеме – Чәнти (мизинец).



**гаилә – семья**

**апа – старшая сестра**

**абый – старший брат**

**сеңел – младшая сестра**

**эне – младший брат**

**4. Гаиләгез турында әйтергә өйрәнегез.** Научитесь говорить о своей семье.

Бу – минем гаиләм.

Бу – минем әнием.

Бу – минем әтием.

Бу – минем әбием.

Бу – минем бабам.

Бу – минем абыем.

Бу – минем апам.

Бу – минем энем.

Бу – минем сеңлем.

**5. Әти-әниегезнең һәм туганнарыгызның фотоларын алып килегез һәм алар турында әйтегез.** Принесите фотографии родителей и родственников, расскажите о них.

**Истә калдырыгыз!** Запомните!

**Исемнең тартым белән төрләнеше** (склонение имен существительных по принадлежности)

| | |
|---|---|
| (минем) әби**ем** – моя бабушка | апа**м** – моя старшая сестра |
| (синең) әби**ең** – твоя бабушка | апа**ң** – твоя старшая сестра |
| (аның) әби**се** – его (её) бабушка | апа**сы** – его (её) старшая сестра |
| (безнең) әби**ебез** – наша бабушка | апа**быз** – наша старшая сестра |
| (сезнең) әби**егез** – ваша бабушка | апа**гыз** – ваша старшая сестра |
| (аларның) әби**ләре** – их бабушки | апа**лары** – их старшие сёстры |

6. **Тыңлагыз һәм укыгыз.** Прослушайте и прочитайте.

**Бу синең әбиеңме? Әйе, бу – минем әбием.**

**Бу сезнең апагызмы? Әйе, бу – безнең апабыз.**

**Бу синең энеңме? Юк, бу – минем энем түгел.**

**Бу аның сеңлесеме? Әйе, бу – аның сеңлесе.**

**7. Сорауларга җавап бирегез.** Ответьте на вопросы.

Энең бармы? Сеңлең бармы? Апаң бармы? Абыең бармы?

**8. Укыгыз.** Прочитайте.

Бу кемнең әнисе? Бу – Зөһрәнең әнисе.

Бу кемнең әтисе? Бу – Зөлфәтнең әтисе.

Бу кемнең әбисе? Бу – Маратның әбисе.

Бу кемнең бабасы? Бу – Азатның бабасы (бабае).

**Истә калдырыгыз!** Запомните!

***-ның/-нең* – иялек килеше кушымчалары** (аффиксы притяжательного падежа)

**Кемнең?** Кого? Гөлназ**ның**, Рөстәм**нең**

**9. Укыгыз һәм үрнәк буенча әйтегез.** Прочитайте и скажите по образцу.

Бу – минем апам. Аның исеме – Гөлназ.

Бу – минем абыем. Аның исеме – Рөстәм.

Бу – минем әбием. Аның исеме – Сөембикә.

Бу – минем бабам. Аның исеме – Сөләйман.

**исем – имя**

**10. Сорауларга җавап бирегез.** Ответьте на вопросы.

Апаң бармы? Аның исеме ничек?

Абыең бармы? Аның исеме ничек?

Энең бармы? Аның исеме ничек?

Сеңлең бармы? Аның исеме ничек?

**Истә калдырыгыз!** Запомните!

**Микъдар саннары.** Количественные числительные

**0 – ноль**
**1 – бер**
**2 – ике**
**3 – өч**
**4 – дүрт**
**5 – биш**
**6 – алты**
**7 – җиде**
**8 – сигез**
**9 – тугыз**
**10 – ун**

**11 – унбер**
**19 – унтугыз**
**20 – егерме**
**30 – утыз**
**40 – кырык**
**50 – илле**
**60 – алтмыш**
**70 – җитмеш**
**80 – сиксән**
**90 – туксан**
**100 – йөз**

**1000 – мең**



**11. Дөрес әйтегез.** Скажите правильно.

11 – унбер, 22 – егерме ике, 33 – утыз өч, 44 – кырык дүрт, 55 – илле биш, 66 – алтмыш алты, 77 – җитмеш җиде, 88 – сиксән сигез, 99 – туксан тугыз.

**12. Тыңлагыз һәм укыгыз.** Прослушайте и прочитайте.

**Ничә яшь?** Сколько лет?

**Син кем? Мин – Гөлинә. Сиңа ничә яшь? Миңа җиде яшь.**
**Бу кем? Бу – Зөлфәт. Аңа ничә яшь? Аңа уналты яшь.**



**13. Җөмләләрне дәвам итегез.** Продолжите предложения.

Мин – ... . Миңа ... яшь.
Бу – әнием. Аңа ... яшь.
Бу – әтием. Аңа ... яшь.
Бу – дәү әнием. Аңа ... яшь.
Бу – дәү әтием. Аңа ... яшь.

**14. Үрнәк буенча үзегез һәм гаиләгез турында сөйләгез.** Расскажите о себе и своей семье по образцу.

Минем исемем ... . Миңа ... яшь. Мин ... (Казаннан, Самарадан, Мәскәүдән). Минем ... (әнием, әтием, әбием, бабам, апам, абыем, энем, сеңлем) бар. Әниемнең (әтиемнең, әбиемнең, бабамның, апамның, абыемның, энемнең, сеңлемнең) исеме ... . Аңа ... яшь. Гаиләбез бик тату.

**тату – дружный**

**15. Диалогларны тыңлагыз һәм укыгыз.** Прослушайте диалоги и прочитайте.

**— Исәнме, Гүзәл!**
**— Сәлам, Рүзәл!**
**— Гүзәл, сиңа ничә яшь?**
**— Миңа җиде яшь. Ә сиңа ничә яшь?**
**— Миңа алты яшь.**





***

**— Исәнме, әбием!**
**— Хәерле көн, улым.**
**— Әбием, сиңа ничә яшь?**
**— Сиксән яшь, улым.**



***

**— Хәерле кич, бабай!**
**— Исәнме, кызым.**
**— Бабай, сиңа ничә яшь?**
**— Туксан дүрт, кызым.**



**16. Диалогларны тулыландырыгыз.** Дополните диалоги.

— Апаң ...?
— ... .
— Аңа ... яшь?
— ... .

***

— Бу ... әбисе?
— Бу – ... .
— Аңа ... яшь?
— ... яшь.

***

— Зөфәрнең абыйсы ...?
— Бар.
— Аңа ...?
— Егерме алты.

**17. Сораулар куегыз һәм җөмләләрне укыгыз.** Поставьте вопросы и прочитайте предложения.

...? Бу – минем апам.
...? Аңа егерме алты яшь.
...? Бабамның исеме – Сөләйман.
...? Әбиемнең исеме – Зөбәрҗәт.
...? Аңа җитмеш биш яшь.
...? Бу кызлар Саратовтан.
...? Бу малайлар Кировтан.
...? Мин Татарстаннан, Казаннан.
...? Миңа ундүрт яшь.

**18. Диалогны укыгыз һәм үрнәк буенча төзегез.** Прочитайте диалог и составьте по образцу.

— Исәнмесез!
— Хәерле көн!
— Таныш булыйк, Сез кем?
— Мин – Зөһрә. Ә Сез кем?
— Ә мин – Йосыф.
— Мин бик шат, Йосыф!
— Мин дә бик шат, Зөһрә.
— Йосыф, Сез кайдан?
— Мин Австралиядән, Мельбурннан. Ә Сез кайдан, Зөһрә?
— Ә мин Россиядән, Оренбургтан.
— Йосыф, Сезгә ничә яшь?
— Миңа унтугыз яшь. Ә Сезгә?
— Миңа да унтугыз яшь. Йосыф, Сез студентмы?
— Әйе, мин – студент. Ә Сез?
— Мин дә студент.
— Рәхмәт, сау булыгыз, Зөһрә!
— Сезгә дә рәхмәт, Йосыф, сау булыгыз.

**рәхмәт – спасибо**

**Сезгә дә рәхмәт! – Вам тоже спасибо!**

**19. Тизәйткечне тыңлагыз һәм истә калдырыгыз.** Прослушайте скороговорку и запомните.



**Мич башында биш мәче,**
**Биш мәченең биш башы.**
**Биш мәченең биш башына**
**Ишелмәсен мич ташы.**

**20. Дөрес әйтегез.** Скажите правильно.

о – [о:] – мон, кол        ө – [ө] – өч, гөл

[ŏ] – том, паром

**21. Дөрес языгыз.** Напишите правильно.

*О о* ____________________

*Ө ө* ____________________

**22.** Саннарны сүзләр белән языгыз. Напишите  числа словами.

1 ________________ 2 ____________________

11 ________________ 12 ____________________

☑ **ҮЗ-ҮЗЕГЕЗНЕ ТИКШЕРЕГЕЗ!** ПРОВЕРЬТЕ СЕБЯ!

1. **Дөрес җавапны табыгыз.** Найдите правильный ответ.

Бу – минем апа...

1) -сы 2) -м 3) -ң

Бу – аның әни...

1) -е 2) -ң 3) -се

Бу – безнең эне...

1) -без 2) -гез 3) -ләре

Бу – синең әби...

1) -ләре 2) -ең 3) -се

Бу – Зөбәрҗәтнең  апа...

1) -сы 2) -е 3) -се

Бу – Зөлфәтнең баба...

1) -ң 2) -м 3) -сы

Бу – аларның бала...

1) -ләре 2) -лары 3) -нары

Бу – кемнең  абый...?

1) -сы 2) -се 3) -е

2. **Дөрес тәрҗемәне табыгыз.** Найдите правильный перевод.

**Рәхмәт**

1) имя 2)  до свидания 3) спасибо

**Ничә**

1) кто 2) сколько 3) откуда

**Энем**

1) мой старший брат 2) его младший брат 3) мой младший брат

**Илле**

| | | |
|---|---|---|
| 1) 40 | 2) 60 | 3) 50 |

**Унҗиде**

| | | |
|---|---|---|
| 1) 11 | 2) 17 | 3) 28 |

**3. Коммуникатив биремнәр.** Коммуникативные задания.

1) Спросите у друга (подруги), есть ли у него (неё) старшая сестра.
2) Как скажете о том, что у вас есть старший брат и ему 25 лет?
3) Как скажете о том, что у вас нет сестры?
4) Пожелайте сестре доброго дня.
5) Пожелайте брату доброго утра.
6) Пожелайте бабушке доброго вечера.
7) Скажите, что это младшая сестра Зульфата.
8) Скажите, что это младший брат Зухры.
9) Пожелайте дедушке доброго пути.
10) Скажите, как Вас зовут, откуда Вы и сколько Вам лет.



## **МИН ҺӘМ МИНЕМ ДУСЛАРЫМ.** Я И МОИ ДРУЗЬЯ

**1. Тыңлагыз һәм укыгыз.** Прослушайте и прочитайте.

**Бу – минем дустым.**

**Аның исеме – Филүс.**

**Аңа ундүрт яшь.**

**Ул Мәскәүдән.**

**дус – друг**

**Истә калдырыгыз!** Запомните!
**(минем) дустым** – мой друг
**(синең) дустың** – твой друг
**(аның) дусты** – его (её) друг
**(безнең) дустыбыз** – наш друг
**(сезнең) дустыгыз** – ваш друг
**(аларның) дуслары** – их друзья



**2. Үрнәк буенча дустыгыз турында әйтегез.** Расскажите о друге (подруге) по образцу.
*Үрнәк:* Бу – минем дустым. Аның исеме – Филүсә. Аңа унсигез яшь. Ул Яр Чаллыдан.

**3. Диалогларны тыңлагыз һәм укыгыз.** Прослушайте диалоги и прочитайте.

— Гүзәл, дустың бармы?

— Әйе, бар.

— Исеме ничек?

— Гөлнур.

— Ул кайдан?

— Красноярскидан.

***

— Сәлам, Мансур!

— Сәлам! Артур, бу кемнең фотосы?

— О-о-о, бу – минем дустым.

— Шулаймыни?

— Әйе, шулай. Аның исеме – Илнур.

— Аңа ничә яшь?

— Егерме бер.

— Ул кайдан?

—Ул Украинадан.

**Шулаймыни? – Разве?**

**4. Җөмләләрне дәвам итегез.** Продолжите предложения.

Бу – Илсурның дусты. Аның исеме – ... . Аңа ... яшь.

Бу – Фирүзәнең дусты. Аның исеме – ... . Аңа ... яшь.

Бу кемнең ...? Аның исеме ...? Аңа ... яшь?

**5. Тыңлагыз һәм укыгыз.** Прослушайте и прочитайте.

Минем дусларым күп.

Аларның исемнәре: Рушан, Булат, Тимур.

Рушан Екатеринбургтан, Булат Иркутскидан,

Тимур Одессадан.

Алар – яхшы дуслар.

**күп – много**

**аз – мало**



**6. Дусларыгызның фотоларын күрсәтегез һәм алар турында әйтегез.** Покажите фотографии друзей и скажите о них.

*Үрнәк: Бу – минем дусларым. Аларның исемнәре ... .*

**7. Диалогларны укыгыз.** Прочитайте диалоги.

— Сәлам, Илнур!
— Хәлләр ничек, Айнур?
— Рәхмәт, яхшы. Ә Син нихәл?
— Ал да гөл, рәхмәт.

***

— Сәлам, Дилүсә!
— Исәнме, Гөлүсә!
— Хәлләрең яхшымы?
— Яхшы, рәхмәт. Ә синең хәлләрең ничек?
— Ярыйсы, рәхмәт.

***

— Исәнмесез, Гүзәл ханым!
— Исәнмесез, Рүзәл әфәнде!
— Хәлләрегез ничек?
— Рәхмәт, бик яхшы. Ә Сез нихәл?
— Беркөе, рәхмәт.

**Хәлләр ничек (нихәл)? – Как дела?**

**Яхшы (әйбәт) – хорошо**

**Шәп – отлично**

**Бик яхшы – очень хорошо**

**Ал да гөл – всё прекрасно**

**Ярыйсы – ничего**

**Беркөе – по-прежнему**

**Начар – плохо**

**8. Диалогларны тулыландырыгыз.** Дополните диалоги.

— ..., дустым!
— ...!
— Хәлләрең ...?
— Рәхмәт, ... .

***

— Исәнмесез, ...!
— ...!
— Хәлләрегез ничек?
— ... .

**9. Җавап бирегез.** Ответьте на вопросы.

Ничә? … . Ничек? … . Кайдан? … . Кем? … . Кемнең? … .

**10. Тыңлагыз һәм укыгыз.** Прослушайте и прочитайте.

**Нинди?** Какой? Какая? Какое?

**Дусларым күп. Иң якын дустым – Нурбәк.**
**Ул Татарстаннан, Мамадыштан.**
**Аңа егерме өч яшь.**
**Ул – бик акыллы, күңелле, юмарт, ярдәмчел кеше.**

**иң якын – самый близкий**

**акыллы – умный**

**юмарт – щедрый**

**күңелле – весёлый**

**ярдәмчел – отзывчивый**

**кызык – интересный**

**11. Җөмләләрне дәвам итегез.** Продолжите предложения.

Дусларым … . Иң якын дустымның исеме … . Аңа … . Ул – … кеше.

**12. Сорауларга җавап бирегез.** Ответьте на вопросы.

А) Дусларың күпме? Иң якын дустың кем? Аңа ничә яшь? Ул кайдан? Дустың нинди кеше?

Ә) Бу кеше юмартмы? Бу кыз нинди? Бу малай нинди? Бу туташ нинди? Бу балалар ярдәмчелме? Бу әфәнде кызыкмы?

**13. Татар мәкальләрен укыгыз һәм истә калдырыгыз.** Прочитайте и запомните татарские пословицы.

*Кош – канаты белән, кеше дуслары белән көчле.
(Птица сильна крыльями, а человек – дружбой.)
*Дустың булмаса – эзлә, тапсаң – югалтма.
(Нет друга – ищи, нашёл – не потеряй.)

**14. Иң якын дустыгыз турында сөйләгез.** Расскажите о самом близком друге.

Иң якын дустымның исеме – … . Ул … (Татарстаннан, Украинадан, Төркиядән, Үзбәкстаннан). Аңа … яшь. Дустым – бик … (акыллы, юмарт, ярдәмчел, кызык) кеше.



**15. Тыңлагыз һәм укыгыз.** Прослушайте и прочитайте.

**Сәгать ничә?** Который час?

**Сәгать өч.**

**Ундүрт сәгать егерме минут.**

**Ун тулырга биш минут.**

**Тугызынчы ярты.**

**Сигезенче унбиш минут.**

**Истә калдырыгыз!** Запомните!

***-ынчы / -енче, -нчы / -нче*** **– тәртип саннары кушымчалары** (аффиксы порядковых числительных)

**бер – беренче; ун – унынчы; ике – икенче; алты – алтынчы**

**16. Диалогларны укыгыз.** Прочитайте диалоги.

**Исән-сау булыгыз! –**
**Будьте здоровы!**
**На здоровье!**



— Гафу итегез, сәгать ничә?

— Сәгать дүрт.

— Рәхмәт.

— Исән-сау булыгыз!

***



— Гүзәл, хәзер сәгать бишме?

— Юк, биш тулырга ун минут.

— Рәхмәт.

— Исән-сау бул!

***



— Фәнүзә ханым, гафу итегез, хәзер сәгать ничә?

— Унберенче ярты.

— Рәхмәт.

— Исән-сау булыгыз!

17. **Диалогларны тулыландырыгыз.** Дополните диалоги.

— Дустым, сәгать ...?

— ... .

— Рәхмәт.

— ... .

***

— Әби, хәзер сәгать ...?

— Юк, хәзер ...

***

— Бабай, сәгать ...?

— ... ярты.

***

— Гафу ит, Нурбулат, сәгать ... ун минутмы?

— Юк, ... унбиш минут.

— ... .

— Исән-сау бул.

**18. Татарча әйтегез.** Скажите по-татарски.

Который час?

Сейчас – половина шестого.

Время – без пяти семь.

Сейчас – десять минут девятого.

Время – ровно восемь.

**19. Укыгыз һәм билге куегыз.** Прочитайте и поставьте знак.

Минем дустым ... .

| | | | |
|---|---|---|---|
| Ярдәмчел | ○ | Оптимист | ○ |
| Юмарт | ○ | Пессимист | ○ |
| Кызык | ○ | Актив | ○ |

**20. Дөрес әйтегез.** Скажите правильно.

у – [у] – бу, ун
[w] – тәүге

ү – [ү] – дүрт, күл
[w] – дәү, бәү

**21. Дөрес языгыз.** Напишите правильно.

Ү ү ________________________________

Ү ү ________________________________

**22. Саннарны сүзләр белән языгыз.** Напишите числа словами.

3 ____________ 4 ____________

13 ____________ 14 ____________

## ☑ ҮЗ-ҮЗЕГЕЗНЕ ТИКШЕРЕГЕЗ! ПРОВЕРЬТЕ СЕБЯ!

**1. Дөрес җавапны табыгыз.** Найдите правильный ответ.

Дустымның исем... – Айнур.

1) -ы 2) -е 3) -ң

Дустым Уфа... .

1) -дән 2) -нан 3) -дан

Аңа 19 яшь.

1) унсигез 2) унтугыз 3) уналты

Минем дуслар... – күңелле кешеләр.

1) -ым 2) -ем 3) -ы

Сәгать алты... ярты.

1) -ынчы 2) -нчы 3) -нче

Сәгать ун... егерме минут.

1) -ынчы 2) -нчы 3) -нче

Бу – Мансурның дуст... .

1) -е 2) -ы 3) -м

Дусларымның исем... – Азат, Булат, Самат.

1) -ләре 2) -лары 3) -нәре

2. **Дөрес җавапны табыгыз.** Найдите правильный ответ.

**юмарт**

1) умный　　2) щедрый　　3) весёлый

**шәп**

1) хорошо　　2) плохо　　3) отлично

**дустыбыз**

1) мой друг　　2) его друг　　3) наш друг

**бишенче**

1) седьмой　　2) третий　　3) пятый

**унсигезенче**

1) одиннадцатый　　2) восьмой　　3) восемнадцатый

3. **Коммуникатив биремнәр.** Коммуникативные задания.

1) Спросите у прохожего, который час.
2) Скажите, что сейчас половина второго.
3) Уточните у друга (подруги), сколько минут девятого.
4) Как скажете о том, что Ваш друг очень отзывчивый и щедрый?
5) Спросите у брата, как зовут его самого близкого друга.
6) Спросите у сестры, много ли у неё друзей.
7) Поинтересуйтесь у бабушки, как у неё дела.
8) Скажите, что это ваш друг, он из Испании.
9) Скажите, что это ваша подруга, она из Америки.
10) Пожелайте друзьям доброго пути.



ҺӨНӘРЛӘР. УКУ ҺӘМ ЭШ. ПРОФЕССИИ. УЧЁБА И РАБОТА

1. **Тыңлагыз һәм укыгыз.** Прослушайте и прочитайте.

**Кайда эшли?** Где работает?

**Кем булып эшли?** Кем работает?

Бу – укытучы. Ул мәктәптә эшли.
Бу – төзүче. Ул фирмада эшли.
Бу – сатучы. Ул кибеттә эшли.
Бу – менеджер. Ул супермаркетта эшли.
Бу – хисапчы. Ул заводта эшли.
Бу – китапханәче. Ул китапханәдә эшли.
Сез кайда эшлисез? Мин университетта эшлим.
Сез кем булып эшлисез? Мин укытучы булып эшлим.

**укытучы – учитель**
**төзүче – строитель**
**сатучы – продавец**
**хисапчы – бухгалтер**
**китапханәче – библиотекарь**
**тәрҗемәче – переводчик**

2. **Җөмләләрне тулыландырыгыз.** Дополните предложения.

Бу – минем апам. Ул ... эшли.

Бу – минем абыем. Ул ... эшли.

Бу – минем әнием. Ул ... эшли.

Бу – минем әтием. Ул ... эшли.

Бу – минем дустым. Ул ... эшли.

**Истә калдырыгыз!** Запомните!

***Эшләргә*** (работать) / ***эшләмәскә*** (не работать) **фигыленең хәзерге заманда төрләнеше** (спряжение глагола в настоящем времени)

| | |
|---|---|
| **Мин эшлим/эшләмим** | **Без эшлибез/эшләмибез** |
| **Син эшлисең/эшләмисең** | **Сез эшлисез /эшләмисез** |
| **Ул эшли/эшләми** | **Алар эшлиләр/эшләмиләр** |

3. **Сорауларга җавап бирегез.** Ответьте на вопросы.

Сез эшлисезме? Сез кайда эшлисез? Сез кем булып эшлисез?

Дустыгыз эшлиме? Ул кайда эшли? Ул кем булып эшли?

Апагыз кайда һәм кем булып эшли?

4. **Рәсемнәргә карагыз һәм җавап бирегез.** Посмотрите на рисунки и ответьте.



Бу ханым кайда эшли?



Бу әфәнде кайда эшли?




Бу туташ кайда эшли?



Бу туташ кайда эшли?

**Истә калдырыгыз!** Запомните!
*-да/-дә, -та/-тә* **– урын-вакыт килеше кушымчалары** (аффиксы местно-временного падежа)
**Кайда?** Где?
стадион**да**, китапханә**дә**, парк**та**, кибет**тә**
Самара**да**, Мәскәү**дә**, Ташкент**та**, Әлмәт**тә**

**5. Диалогны укыгыз һәм үрнәк буенча төзегез.** Прочитайте диалог и составьте по образцу.

— Сәлам, Айсылу!
— Исәнме, Бану!
— Хәлләр ничек, Айсылу?
— Рәхмәт, ярыйсы. Ә син нихәл, Бану?
— Яхшы, рәхмәт.
— Бану, синең әниең укытучымы?
— Юк, ул – китапханәче. Ә синең әниең кем булып эшли?
— Әнием – төзүче. Ул зур фирмада эшли.

**6. Җөмләләрне дәвам итегез.** Продолжите предложения.

Бу апа китапханәдә эшләми, ул ... .
Бу абый төзүче түгел, ул ... .
Бу туташ кибеттә эшләми, ул ... .
Бу әфәнде аквапаркта эшләми, ул ...

**7. Шигырьне тыңлагыз һәм сәнгатьле итеп укыгыз.** Прослушайте и прочитайте выразительно стихотворение.

**Шофёр булам**

Мин дә, әтием шикелле,
Шофёр булырга уйлыйм.
Шуның өчен һәрвакыт
Машина белән уйныйм.

Тизрәк үсеп, шофёр булсам,
Нишләргә белер идем:
Урамдагы бар баланы
Утыртып йөрер идем.

*Зәкия Туфайлова*

8. **Тыңлагыз һәм укыгыз.** Прослушайте и прочитайте.

**Кайда укый?** Где учится?

**Ничәнче сыйныфта (курста) укый?** В каком классе (на каком курсе) учится?

Бу – укучы. Ул мәктәптә укый.
Ул сигезенче сыйныфта укый.
Бу – студент. Ул университетта укый.
Ул өченче курста укый.
Бу – Энҗе ханым. Ул курсларда укый.

**укучы – ученик**





**9. Сорауларга җавап бирегез.** Ответьте на вопросы.
Бу кыз ничәнче мәктәптә укый?
Бу малай ничәнче гимназиядә укый?
Бу укучы ничәнче сыйныфта укый?
Бу студент ничәнче курста укый?



**10. Үзегез һәм дустыгыз турында әйтегез.** Скажите о себе и о своём друге (подруге).

А) Минем исемем – ... . Миңа ... яшь. Мин ... (мәктәптә, гимназиядә, лицейда, университетта, курсларда) укыйм.

Ә) Иң якын дустым – ... . Аңа ... яшь. Дустым ... (мәктәптә, гимназиядә, лицейда, университетта) укый.

**Истә калдырыгыз!** Запомните!

***Укырга*** (учиться, читать) / ***укымаска*** (не учиться, не читать) **фигыленең хәзерге заманда төрләнеше** (спряжение глагола в настоящем времени)

| | |
|---|---|
| **Мин укыйм / укымыйм** | **Без укыйбыз / укымыйбыз** |
| **Син укыйсың / укымыйсың** | **Сез укыйсыз / укымыйсыз** |
| **Ул укый / укымый** | **Алар укыйлар / укымыйлар** |

**11. Укыгыз һәм үрнәк буенча җөмләләр төзегез.** Прочитайте и составьте предложения по образцу.

Бу укучы ничәнче мәктәптә укый? Ул тугызынчы мәктәптә укый.

Ул ничәнче сыйныфта укый? Ул унынчы сыйныфта укый.

Бу укучы ничек укый? Ул бик яхшы укый.

Бу әфәнде нәрсә укый? Ул журнал укый.

Син бу китапны укыйсыңмы? Әйе, мин бу китапны укыйм.

**12. Җөмләләрне дәвам итегез.** Продолжите предложения.

Мин техникумда укымыйм, мин ... .

Апам укымый, ул ... .

Абыем университетта укымый, ул ... .

Бу кызлар унсигезенче мәктәптә укымыйлар, алар ... .

Без гимназиядә укымыйбыз, без ... .

**13. Укыгыз һәм мәктәбегез турында сөйләгез.** Прочитайте и расскажите о своей школе.

Мин мәктәптә укыйм. Мәктәптә 1200 укучы укый. Мәктәбебез бик яхшы. Укытучыларыбыз да бик яхшы. Мин мәктәбемне дә, укытучыларыбызны да яратам.

**Истә калдырыгыз!** Запомните!

**-не/-ны – төшем килеше кушымчалары** (аффиксы винительного падежа)

**Кемне? Нәрсәне?** Кого? Что?

дусларым**ны; **мәктәбем**не**

**14. Дөрес әйтегез.** Скажите правильно.

А) Бу – минем мәктәб... . Бу мәктәп... 800 укучы укый. Безнең мәктәб... бик яхшы. Без мәктәб... яратабыз.

**Ә)** Минем дуслар... күп. Алар мәктәп... укыйлар. Дуслар... – күңелле, ярдәмчел кеше... Мин дусларым... яратам.

**15. Диалогларны тулыландырыгыз.** Дополните диалоги.

— Фазыл, син ... укыйсың?

— Мин гимназиядә ... .

***

— Айсылу, син нәрсә ...?

— Мин газета ... .

— Бу газета ...?

— Әйе, ...

***

— Эльвира, дустың ... мәктәптә ...?

— ... мәктәптә.

— ... сыйныфта?

— ... сыйныфта.

— Ул ничек ...?

— Бик яхшы ... .

**16. Сораулар куегыз һәм укыгыз.** Поставьте вопросы и прочитайте.

...? Мин курсларда укыйм.

...? Без җиденче гимназиядә укыйбыз.

...? Дустым бик яхшы укый.

...? Бабай журнал укый.

...? Бу кыз унберенче сыйныфта укый.

...? Бу малай дүртенче сыйныфта укый.

...? Алар университетта укыйлар.

**17. Тыңлагыз һәм укыгыз.** Прослушайте и прочитайте.

**Кая бара?** Куда идёт?

Бу укучы кая бара? Ул мәктәпкә бара.
Бу әфәнде кая бара? Ул эшкә бара.
Син кая барасың? Мин китапханәгә барам.
Сез кая барасыз? Без стадионга барабыз.
Алар кая баралар? Алар кафега баралар.
Бу туристлар кая баралар? Алар Төркиягә баралар.
Бу кешеләр кая баралар? Алар Кытайга баралар.

**эш – работа**

**Төркия – Турция**

**Кытай – Китай**

**Истә калдырыгыз!** Запомните!

*-га/-гә, -ка/-кә* – **юнәлеш килеше кушымчалары** (аффиксы направительного падежа)

**Кая?** Куда?

стадион**га**, китапханә**гә**, парк**ка**, кибет**кә**

Самара**га**, Мәскәү**гә**, Ташкент**ка**, Әлмәт**кә**

**18. Рәсемнәргә карагыз һәм җавап бирегез.** Посмотрите на рисунки и ответьте.




Бу ханым кая бара?




Бу әфәнде кая бара?




Бу туташ кая бара?




Бу кыз кая бара?

**19. Диалогларны укыгыз һәм үрнәк буенча төзегез.** Прочитайте диалоги и составьте по образцу.

— Хәерле көн, Эльмира!
— Исәнме, Эльвира!
— Эльмира, хәзер син кая барасың?
— Кибеткә. Ә син?
— Мин дә кибеткә барам.
— Әйдә бергә барабыз.
— Ярар, яхшы.

**бергә – вместе**

**ярар – ладно**

***

— Хәерле кич, дустым!
— Сәлам!
— Кая барасың?
— Кинога. Ә син кая?
— Мин театрга барам.
— Хәерле юл сиңа! Сау бул!
— Сау бул! Сиңа да хәерле юл!

**Истә калдырыгыз!** Запомните!

***Барырга*** (идти, ехать) / бармаска (не идти, не ехать) **фигыленең хәзерге заманда төрләнеше** (спряжение глагола в настоящем времени)

| | |
|---|---|
| **Мин барам/бармыйм** | **Без барабыз/бармыйбыз** |
| **Син барасың/бармыйсың** | **Сез барасыз /бармыйсыз** |
| **Ул бара/бармый** | **Алар баралар/бармыйлар** |

**20. Җөмләләрне дәвам итегез.** Продолжите предложения.

Мин университетка бармыйм, мин ... .
Ул стадионга бармый, ул ... .
Без паркка бармыйбыз, без ... .
Алар Америкага бармыйлар, алар ... .
Бу ханымнар Германиягә бармыйлар, алар ... .
Бу әфәнделәр Мәскәүгә бармыйлар, алар ... .
Бу укучылар музейга бармыйлар, алар ... .

**21. Дөрес әйтегез.** Скажите правильно.

ы – [ы̆] – тугыз, ханым
[ы] – сыр, брынза

э – [э̆] – эт, эне
[э] – эфир, этнос

**22. Дөрес языгыз.** Напишите правильно.

*Ы ы* ______________________________

*Э э* ______________________________

**23. Саннарны сүзләр белән языгыз.** Напишите числа словами.

5 ________________ 6 ________________

15 ________________ 16 ________________

☑ **ҮЗ-ҮЗЕГЕЗНЕ ТИКШЕРЕГЕЗ!** ПРОВЕРЬТЕ СЕБЯ!

**1. Дөрес җавапны табыгыз.** Найдите правильный ответ.

Дустым мәктәп... укый.
1) -та 2) -тә 3) -дә

Бу укучы сигезенче сыйныф... укый.
1) -дә 2) -тә 3) -та

Бу студент университет... укый.
1) -та 2) -тә 3) -да

Бу ханым кибет... эшли.
1) -та 2) -тә 3) -кә

Бу әфәнде кафе... эшли.
1) -дә 2) -да 3) -га

Туристлар Кытай... баралар.
1) -гә 2) -ка 3) -га

Без кино... барабыз.
1) -гә 2) -да 3) -га

Мин гаиләм... бик яратам.
1) -гә 2) -не 3) -дә

2. **Дөрес тәрҗемәне табыгыз.** Найдите правильный перевод.

**эшлибез**

| | | |
|---|---|---|
| 1) работают | 2) работаем | 3) работаете |

**мәктәптә**

| | | |
|---|---|---|
| 1) в школу | 2) в школе | 3) школу |

**сатучы**

| | | |
|---|---|---|
| 1) строитель | 2) продавец | 3) учитель |

**төзүче**

| | | |
|---|---|---|
| 1) библиотекарь | 2) переводчик | 3) строитель |

**барасың**

| | | |
|---|---|---|
| 1) идут | 2) идёшь | 3) идём |

**тәрҗемәче**

| | | |
|---|---|---|
| 1) строитель | 2) переводчик | 3) учитель |

3. **Коммуникатив биремнәр.** Коммуникативные задания.

1) Спросите девушку, где она работает.
2) Как скажете о том, что вы учитесь на курсах?
3) Уточните у друга (подруги), где работает его (её) сестра.
4) Поинтересуйтесь у бабушки, что она читает.
5) Спросите брата, куда он идёт.
6) Спросите туристов, куда они едут и пожелайте им доброго пути.
7) Как скажете о том, что Ваш друг (подруга) работает в кафе официантом?
8) Скажите о себе, где вы учитесь или где и кем работаете.
9) Скажите, что Вы работаете не в банке, а в фирме.
10) Скажите, что вы любите своих друзей. Они очень добрые, щедрые и весёлые.




## **ТЕЛЛӘР БЕЛҮ.** ЗНАНИЕ ЯЗЫКОВ

**1. Тыңлагыз һәм укыгыз.** Прослушайте и прочитайте.

**Сез нинди телләр беләсез?** Какие языки Вы знаете?

**Син ничә тел беләсең?**
**Мин өч тел беләм: рус теле, татар теле, инглиз теле.**
**Син нинди телләр беләсең?**
**Мин русча, татарча, инглизчә беләм.**
**Мин русча яхшы беләм, ә татарча бераз беләм.**
**Син испанча беләсеңме?**
**Юк, испанча белмим.**
**Ә Сез төрекчә беләсезме?**
**Без төрекчә бик яхшы беләбез.**

**русча – по-русски**

**татарча – по-татарски**

**инглизчә – по-английски**

**испанча – по-испански**

**төрекчә – по-турецки**

**Истә калдырыгыз!** Запомните!

***Белергә*** (знать) / ***белмәскә*** (не знать) **фигыленең хәзерге заманда төрләнеше** (спряжение глагола в настоящем времени)

| | |
|---|---|
| **Мин беләм/белмим** | **Без беләбез/белмибез** |
| **Син беләсең/белмисең** | **Сез беләсез /белмисез** |
| **Ул белә/белми** | **Алар беләләр/белмиләр** |

**2. Диалогларны укыгыз һәм үрнәк буенча төзегез.** Прочитайте диалоги и составьте по образцу.

— Гафу итегез, Сез татарча беләсезме?
— Әйе, бераз беләм.
— Сез Татарстаннанмы?
— Әйе, мин Татарстаннан, Казаннан. Ә Сез кайдан?
— Мин Үзбәкстаннан, Ташкенттан.

***

— Ирек, син инглизчә беләсеңме?
— Бераз беләм.
— Тагын нинди телләр беләсең?
— Русча һәм татарча беләм.
— Татарча яхшы беләсеңме?
— Әлбәттә, татар теле – туган телем.

***

— Ирина, туган телең рус телеме?
— Әйе.
— Тагын нинди чит телләр беләсең?
— Мин берничә тел беләм: французча, испанча, төрекчә яхшы беләм.
— Ә японча беләсеңме?
— Юк, белмим.

**тагын – ещё**

**туган тел – родной язык**

**әлбәттә – конечно**

**берничә тел – несколько языков**

**чит тел – иностранный язык**

**3. Җөмләләрне дәвам итегез.** Продолжите предложения.

Дустым французча белми, ул … .
Апам төрекчә белми, ул … .
Бу укучылар немецча белмиләр, алар … .
Бу ханым инглизчә белми, ул … .
Бу әфәнде испанча белми, ул … .
Бу туристлар русча белмиләр, алар … .

**сөйләшергә – разговаривать**

**әйтергә – сказать**

**сөйләргә – рассказывать**

**өйрәнергә – изучать**

**язарга – написать**

**4. Дөрес әйтегез.** Скажите правильно.

| | | |
|---|---|---|
| Минем | **сүзлегем** | **китабым** |
| Синең | ................ | ................ |
| Аның | ................ | ................ |
| Безнең | ................ | ................ |
| Сезнең | ................ | ................ |
| Аларның | ................ | ................ |

**Истә калдырыгыз!** Запомните!

***Ул нишли? Ул укый, эшли, бара, белә*** – хәзерге заман **хикәя фигыльләр** (глаголы настоящего времени изъявительного наклонения)

**5. Җөмләләрне тулыландырыгыз.** Дополните предложения.

Мин татарча … укыйм. Апам тәрҗемәче булып … . Ул берничә … белә. Дустымның туган теле – … теле. Алар … белмиләр. Без … беләбез.

**6. Тыңлагыз һәм укыгыз.** Прослушайте и прочитайте.

Мин татарча, русча, инглизчә сөйләшәм.
Ул татарча монолог сөйли.
Без укытучыга рәхмәт әйтәбез.
Алар биремнәр язалар.
Укучылар сорауларга җавап бирәләр.
Мин укытучыны аңлыйм.
Без сүзләрне кабатлыйбыз.
Алар татарча дисклар тыңлыйлар.
Укучылар берничә тел өйрәнәләр.

**җавап бирергә – ответить**

**кабатларга – повторять**

**аңларга – понимать**

**тыңларга – слушать**

**дәрес – урок**

**бирем – задание**

**7. Сорауларга җавап бирегез.** Ответьте на вопросы.

Син ничә тел беләсең? Син кытайча беләсеңме? Сез японча сөйләшәсезме? Ул дәрестә нәрсә яза? Алар кемгә рәхмәт әйтәләр? Бу сорауга кем җавап бирә? Сез мине аңлыйсызмы? Алар нәрсә тыңлыйлар? Укучылар нәрсәләр кабатлыйлар? Дәресләрдә сез нишлисез? Татар теле дәресләре кызыкмы?

**8. Сораулар куегыз һәм укыгыз.** Поставьте вопросы и прочитайте.

...? Мин ике тел беләм.

...? Без итальянча белмибез.

...? Дустымның туган теле – төрек теле.

...? Бу кеше немецча сөйләшми.

...? Бу укучы монолог сөйли.

...? Дәрестә без диалоглар укыйбыз.

...? Алар татарча сүзләр язалар.

**9. Җөмләләрне тулыландырыгыз.** Дополните предложения.

Мин ... сөйлим. Син ... сөйләшәсең. Ул ... әйтә. Без ... тыңлыйбыз. Сез ... кабатлыйсыз. Алар ... аңлыйлар.

**10. Тыңлагыз һәм укыгыз.** Прослушайте и прочитайте.

**Сезгә нишләргә кирәк?** Что Вам нужно сделать?

**Сез нишләргә тиеш?** Что Вы должны сделать?

Миңа татарча яхшы белергә кирәк, чөнки дусларым – татарлар.

Мин татарча яхшы белергә тиеш, чөнки татар теле – туган телем.

Миңа бу текстны укырга кирәк.

Сиңа бу сүзләрне кабатларга кирәк.

Аңа бу биремнәрне язарга кирәк.

Безгә бу сорауларга җавап бирергә кирәк.

Сезгә укытучыны тыңларга кирәк.

Аларга диалог сөйләргә кирәк.

Мин Сезгә рәхмәт әйтергә тиеш.

Ул мине аңларга тиеш.

**миңа кирәк – мне нужно, надо**

**мин тиеш – я должен (должна)**

**Истә калдырыгыз!** Запомните!

***Керергә*** (зайти), ***барырга*** (идти), ***чыгарга*** (выйти), ***тәрҗемә итәргә*** (переводить), ***сөйләргә*** (рассказывать) – **фигыльнең инфинитив формалары** (формы инфинитива глагола)

**11. Сорауларга җавап бирегез.** Ответьте на вопросы.

Гафу итегез, хәзер сезгә кая барырга кирәк?
Сез беләсезме, безгә нәрсә укырга кирәк?
Сиңа нәрсә язарга кирәк?
Аларга ничә тел белергә кирәк?
Мин нәрсә әйтергә тиеш?
Без нәрсә кабатларга тиеш?
Алар нишләргә тиеш?

**12. Диалогларны укыгыз.** Прочитайте диалоги.

— Гафу итегез, керергә ярыймы?
— Әйе, ярый, рәхим итегез.
— Рәхмәт.

***

— Дания ханым, чыгарга мөмкинме?
— Әлбәттә, мөмкин.
— Рәхмәт.

**керергә – войти**

**чыгарга – выйти**

**ярый (мөмкин) – можно**

**рәхим итегез – добро пожаловать**

**13. Диалогларны тулыландырыгыз.** Дополните диалоги.

— Исәнмесез, ... ярыймы?
— Әйе, ... .
— ... Сезгә.

***

— Гафу итегез, Илдар әфәнде, ... мөмкинме?
— ... .
— ... .

**14. Укыгыз һәм истә калдырыгыз.** Прочитайте и запомните.

**Кая?** Дәрес**кә**, татар теле дәресе**нә**.

**Нәрсәне?** Дәрес**не**, татар теле дәресе**н**.

**Кайдан?** Дәрес**тән**, татар теле дәресе**ннән**.

**Кайда?** Дәрес**тә**, татар теле дәресе**ндә**.

**15. Дөрес әйтегез.** Скажите правильно.

Син кая барасың? Университет... .

Син кайсы университетка барасың? Казан федераль университеты... .

Син кайда укыйсың? Курслар... .

Син нинди курсларда укыйсың? Татар теле курслары... .

Син кайдан кайтасың? Дәрес... .

Син нинди дәрестән кайтасың? Инглиз теле дәресе... .

**Истә калдырыгыз!** Запомните!

**Кайчан?** Когда? **Сәгать ничәдә?** Во сколько часов?

**Сәгать** бер**дә**, алты**да**, биш**тә**, дүрт сәгать ун минут**та**

**16. Рәсемнәргә карагыз һәм җавап бирегез.** Посмотрите на рисунки и ответьте на вопросы.



Татар теле дәресе сәгать ничәдә башлана?

**башланырга – начинаться**



Татар теле дәресе сәгать ничәдә бетә?

**бетәргә – заканчиваться**




Татар теле дәресе кайда була?

**булырга – быть**

17. **Укыгыз һәм татар теле дәресләре турында сөйләгез.** Прочитайте и расскажите об уроках татарского языка.

Мин татар теле өйрәнәм. Дәресебез сәгать бердә башлана. Дәресләрдә без татарча сөйләшәбез, диалоглар укыйбыз, монологлар сөйлибез, биремнәрне эшлибез. Укытучы безгә сораулар бирә. Без укытучыны тыңлыйбыз, аның сорауларына җавап бирәбез. Без татарча шигырьләр, тизәйткечләр, мәкальләр дә өйрәнәбез. Татар теле дәресләребез бик кызыклы.

18. **Шигырьне тыңлагыз һәм сәнгатьле итеп укыгыз.** Прослушайте и прочитайте выразительно стихотворение.

**Дәү әнидә кунакта**

Җәй көне булдым авылда,
Дәү әнидә кунакта.
Татарча сөйли белергә
Өйрәндем мин шул чакта.

Өйрәнмичә булмый анда,
Русча берни белмиләр.
Әллә уйнап, әллә чынлап:
«По-русски не знай», – диләр.

Тавыклар да, үрдәкләр дә
«Кушай!» – дисәң качалар.
«Аша!» – дисәң, авызларын
Бик зур итеп ачалар...

Киләсе җәйдә әни дә,
Әти дә барыр әле,
Һәм татарча сөйләшергә
Өйрәнеп кайтыр әле.

*Җәвад Тәрҗеманов*

19. **Телләр турындагы мәкальләрне укыгыз.** Прочитайте пословицы о языках.

*Тел Төмәнгә илтә.

(Язык до Киева доведёт.)

*Телләр белгән – илләр белгән.
(Кто знает языки, тот знает и страны.)

**20. «Туган тел» җырын тыңлагыз һәм беренче куплетын өйрәнегез.** Прослушайте песню «Родной язык» и выучите первый куплет.

**21. Дөрес әйтегез.** Скажите правильно.

и - [и] – мин, син, Иркә
Илдар, Илсур

й [й] – йолдыз, йокы
йөз, йөзем

**22. Дөрес языгыз.** Напишите правильно.

*И и* ____________________

*Й й* ____________________

**23. Саннарны сүзләр белән языгыз.** Напишите числа словами.

7 ____________ 8 ____________
17 ____________ 18 ____________

☑ **ҮЗ-ҮЗЕГЕЗНЕ ТИКШЕРЕГЕЗ!** ПРОВЕРЬТЕ СЕБЯ!

1. **Дөрес җавапны табыгыз.** Найдите правильный ответ.

Дустым татар теле дәресе... бара.
1) -нә 2) -тә 3) -кә

Дәрестә без яза... .
1) -сыз 2) -сың 3) -быз

Бу студент Казан университеты... укый.
1) -ка 2) -та 3) -нда

Бу ханым испанча сөйләш... .
1) -а 2) -ә 3) -ый

Бу әфәнде... туган теле – төрек теле.
1) -гә 2) -не 3) -нең

Дәрес сәгать өч... башлана.
1) -кә 2) -тә 3) -та

Без дәрес... барабыз.

1) -гә 2) -кә 3) -тән

Мин татар теле дәресләре... бик яратам.

1) -не 2) -ннән 3) -н

2. **Дөрес тәрҗемәне табыгыз.** Найдите правильный перевод.

**тыңларга**

1) работать 2) слушать 3) повторять

**дәрестә**

1) с урока 2) уроки 3) на уроке

**өйрәнергә**

1) разговаривать 2) изучать 3) читать

**башлана**

1) повторяет 2) изучает 3) начинается

**керергә**

1) спросить 2) выйти 3) войти

**бирем**

1) слово 2) задание 3) предложение

**3. Коммуникатив биремнәр.** Коммуникативные задания.

1) Скажите, сколько языков Вы знаете.
2) Спросите прохожего, говорит ли он по-турецки.
3) Уточните у друга (подруги), на каких языках он (она) разговаривает.
4) Как скажете о том, что ваши уроки начинаются в 18.00.
5) Попросите у учителя разрешения войти.
6) Скажите, что вы делаете на уроках татарского языка.
7) Как скажете о том, что Вам нужно повторить слова?
8) Скажите другу (подруге), что надо знать несколько языков.
9) Скажите пословицу про языки.
10) Скажите, что Вы должны рассказать монолог.



## ЙОРТ. ФАТИР. ДОМ. КВАРТИРА

1. Тыңлагыз һәм укыгыз. Прослушайте и прочитайте.

Сез кайсы шәһәрдә яшисез? В каком городе Вы живёте?

Мин Казанда, Зәкиев урамында, ундүртенче йортта, сиксәненче фатирда яшим.

Дустым Әлмәт шәһәрендә, Тукай урамында, илленче йортта, алтмыш тугызынчы фатирда яши.

Мин тугызынчы катта яшим, ә дустым беренче катта яши.

Без шәһәрдә яшибез, ә әбием авылда яши.

**урам – улица**

**йорт, өй – дом**

**фатир – квартира**

**кат – этаж**

**яңа – новый**

**иске – старый**

Истә калдырыгыз! Запомните!

*Яшәргә* (жить) / *яшәмәскә* (не жить) фигыленең хәзерге заманда төрләнеше (спряжение глагола в настоящем времени)

| | |
|---|---|
| Мин яшим/яшәмим | Без яшибез/яшәмибез |
| Син яшисең/яшәмисең | Сез яшисез /яшәмисез |
| Ул яши/яшәми | Алар яшиләр/яшәмиләр |

2. **Диалогларны укыгыз һәм үрнәк буенча төзегез.** Прочитайте диалоги и составьте по образцу.

— Гафу итегез, Сез кайсы урамда яшисез?

— Ибраһимов проспектында.

— Ничәнче йортта?

— Сиксән беренче йортта.

***

— Гафу итегез, бу егерме дүртенче йортмы?

— Юк. Бу егерме икенче йорт.

— Рәхмәт Сезгә.

— Исән-сау булыгыз.

***

— Хәзер сез яңа йортта яшисезме?

— Әйе, йортыбыз яңа һәм бик матур.

— Сез ничәнче катта яшисез?

— Алтынчы катта.

3. **Рәсемнәргә карагыз һәм сорауларга җавап бирегез.** Посмотрите на рисунки и ответьте на вопросы.




Бу малай ничәнче йортта яши?




Бу кыз ничәнче фатирда яши?




Бу апа ничәнче катта яши?




Бу абый кайсы урамда яши?

Бу фирманың адресы ничек?

*Татарстан Республикасы*
*Казан шәһәре*
*Тукай урамы, 57*
*Телефон: 525-15-55*
*Факс: 525-19-21*

**4. Җөмләләрне тулыландырыгыз.** Дополните предложения.

Мин ... йортта яшим. Ул ... фатирда яши. Алар ... катта яшиләр. Без ... урамында яшибез. Бу кызлар ... районында яшиләр. Бу кешеләр ... шәһәрендә яшиләр.

**5. Җөмләләрне дәвам итегез.** Продолжите предложения.

Мин Казанда яшәмим, ... . Ул Яр Чаллыда яшәми, ... . Без Сахаров урамында яшәмибез, ... . Алар өченче катта яшәмиләр, ... . Дустым унынчы йортта яшәми, ул ... . Әбием сигезенче фатирда яшәми, ул ... .

**6. Тыңлагыз һәм укыгыз.** Прослушайте и прочитайте.

**Бу нинди бүлмә?** Какая это комната?

Бу – кунак бүлмәсе.
Бу – аш бүлмәсе.
Бу – йокы бүлмәсе.
Бу – балалар бүлмәсе.
Бу – эш бүлмәсе.
Бу – юыну бүлмәсе.
Бу – алгы бүлмә.

**аш бүлмәсе – кухня**
**кунак бүлмәсе – гостиная**
**балалар бүлмәсе – детская комната**
**йокы бүлмәсе – спальня**
**юыну бүлмәсе – ванная**
**эш бүлмәсе – рабочий кабинет**
**алгы бүлмә – прихожая**

**7. Рәсемнәргә карагыз һәм сорауга җавап бирегез.** Посмотрите на рисунки и ответьте на вопрос.

Бу нинди бүлмә?








**8. Укыгыз һәм үрнәк буенча үзегезнең фатирыгыз турында әйтегез.** Прочитайте и скажите по образцу о своей квартире.

Фатирыбыз өч бүлмәле.

Фатирыбызда алгы бүлмә, аш бүлмәсе, кунак бүлмәсе, йокы бүлмәсе һәм балалар бүлмәсе бар.

Алгы бүлмә зур түгел.

Аш бүлмәсе якты, уңайлы һәм матур.

Кунак бүлмәсе зур һәм иркен.

Балалар бүлмәсе дә зур һәм матур.

**якты – светлый**

**уңайлы – удобный**

**матур – красивый**

**иркен – просторный**

**9. Җөмләләрне тулыландырыгыз.** Дополните предложения.

Аш бүлмәсе ... . Кунак бүлмәсе ... . Алгы бүлмә ... . Бу – ... бүлмәсе. Бу фатир ... бүлмәле. Бу фатир бик ... .

**10. Сорауларга җавап бирегез.** Ответьте на вопросы.

Бу нинди бүлмә? Алгы бүлмә нинди? Бу кемнең бүлмәсе? Бу ничә бүлмәле фатир? Кайсы бүлмә бик якты? Бу бүлмәләр зурмы?

**11. Сораулар куегыз һәм укыгыз.** Поставьте вопросы и прочитайте.

...? Бу фатир бик иркен.
...? Бу – аш бүлмәсе.
...? Без дүрт бүлмәле фатирда яшибез.
...? Балалар бүлмәсе зур түгел.

**12. Рәсемнәргә карагыз һәм сүзләрне истә калдырыгыз.** Посмотрите на рисунки и запомните слова.

**Бу нәрсә?** Что это?



Бу – өстәл.



Бу – урындык.



Бу – карават.



Бу – кәнәфи.



Бу – диван.



Бу – киштә.



Бу – савыт-саба шкафы.



Бу – кием шкафы.



Бу – суыткыч.



Бу – ишек.



Бу – тәрәзә.



Бу – көзге.

**13. Җөмләләрне дәвам итегез.** Продолжите предложения.

Аш бүлмәсендә ...? Кунак бүлмәсендә ...? Алгы бүлмәдә ...? Йокы бүлмәсендә ...? Эш бүлмәсендә ...? Бүлмәләр ...?

**14. Үрнәк буенча төрле бүлмәләр турында әйтегез.** Скажите по образцу о разных комнатах.

*Үрнәк:* Бу – аш бүлмәсе. Ул зур түгел. Аш бүлмәсендә өстәл, дүрт урындык, суыткыч, савыт-саба шкафы бар.

**анда – там**

**монда – здесь**

**15. Сорауларга җавап бирегез.** Ответьте на вопросы.

Бу нинди бүлмә? Ул зурмы? Анда нәрсәләр бар?

Бу ничәнче йорт? Бу ничәнче фатир? Ул ничәнче катта?

Сез кайсы шәһәрдә яшисез? Сез кайсы урамда яшисез?

**16. Дустыгызга шалтыратыгыз һәм үрнәк буенча аны яңа йортка күчүе белән котлагыз.** Позвоните другу (подруге) и поздравьте его (её) с новосельем по образцу.

— Алло, сәлам, Зилә!
— О-о-о, сәлам, Динә!
— Хәлләрегез ничек?
— Рәхмәт, шәп. Ә син нихәл, Зилә?
— Рәхмәт, яхшы.
— Зилә, яңа фатирыгыз ничек? Хәзер сез кайсы урамда яшисез?
— Хәзер без Бигичев урамында яшибез. Яңа фатирыбыз матур, иркен, якты, биш бүлмәле.
— Шулаймыни?
— Әйе, бик зур.
— Котлыйм сезне!
— Бик зур рәхмәт! Безгә кунакка кил!
— Яхшы. Очрашканга кадәр!

**кунакка кил – приезжай в гости**

**очрашканга кадәр – до встречи**

**17. Йортыгыз һәм фатирыгыз турында сөйләгез.** Расскажите о своём доме и о своей квартире.

Мин .... (Казанда, Әлмәттә, Бөгелмәдә, Самарада), .... (Ибраһимов, Сахаров, Пушкин) урамында, ... (йөзенче, унынчы) йортта, ... (тугызынчы, уналтынчы) фатирда, ... (икенче, алтынчы) катта яшим. Фатирыбыз ... бүлмәле.

Алгы бүлмә ... (зур, кечкенә). Анда ... бар. Аш бүлмәсе ... (якты, матур). Анда ... бар. Кунак бүлмәсе ... (бик зур, иркен). Анда ... бар.

Фатирыбыз бик яхшы һәм матур.

**18. Үрнәк буенча дустыгызның адресын әйтегез.** Скажите по образцу адрес друга (подруги).

Дустымның адресы:

**Казан шәһәре,**
**Әмирхан проспекты,**
**22 нче йорт, 96 нчы фатир.**
**Өй телефоны: 519-21-76**
**Кесә телефоны: 987-654-32-11**

**19. Дөрес әйтегез.** Скажите правильно.

е – [йы] – ел, каен
[йэ] – егерме, биек
[э] – бер

ё – [йо] – самолёт

**20. Дөрес языгыз.** Напишите правильно.

*Е е* ______________________________
*Ё ё* ______________________________

**21. Саннарны сүзләр белән языгыз.** Напишите числа словами.

9 ____________ 20 ____________
19 ____________ 22 ____________

## ☑ ҮЗ-ҮЗЕГЕЗНЕ ТИКШЕРЕГЕЗ! ПРОВЕРЬТЕ СЕБЯ!

1. **Дөрес җавапны табыгыз.** Найдите правильный ответ.

Дустым уникенче йорт... яши.

1) -тә 2) -та 3) -ка

Дәресебез йөз унбишенче аудитория... була.

1) -да 2) -гә 3) -дә

Бу кыз Чехов урамы... яши.

1) -ндә 2) -на 3) -нда

Фатир... өч бүлмәле.

1) -ыбыз 2) -ебез 3) -гыз

Аш бүлмәсе... дүрт урындык бар.

1) -нда 2) -дә 3) -ндә

Бу – алты... кат.

1) -нче 2) -ынчы 3) -нчы

Йортыбыз... йөз кырык фатир бар.

1) -гә 2) -да 3) -дә

Алгы бүлмә... зур көзге бар.

1) -не 2) -ннән 3) -дә

2. **Дөрес тәрҗемәне табыгыз.** Найдите правильный перевод.

**урам**

1) дом 2) квартира 3) улица

**йорт**

1) этаж 2) спальня 3) дом

**суыткыч**

1) холодильник 2) зеркало 3) полка

**иркен**

1) просторный 2) удобный 3) светлый

**савыт-саба**

1) стол 2) посуда 3) стул

**кәнәфи**

1) кровать 2) кресло 3) зеркало

3. **Коммуникатив биремнәрне языгыз.** Напишите коммуникативные задания.

1) Спросите друга (подругу), в какой квартире он (она) живёт.
2) Уточните у прохожего, седьмой ли это дом.
3) Скажите, в каком доме, в какой квартире и на каком этаже вы живёте.
4) Поинтересуйтесь у бабушки, просторная ли её новая квартира.
5) Позвоните другу и спросите, на какой улице он сейчас живёт.
6) Как скажете о том, что вы живёте в трёхкомнатной квартире?
7) Назовите адрес друга.
8) Скажите, что новая квартира большая, светлая и красивая.
9) Как скажете о том, что вам нужен новый холодильник?
10) Назовите номер вашего домашнего телефона.



## ҺАВА ТОРЫШЫ. КӨН. АТНА. АЙ. ЕЛ. ПОГОДА. ДЕНЬ. НЕДЕЛЯ. МЕСЯЦ. ГОД

1. **Тыңлагыз һәм укыгыз.** Прослушайте и прочитайте.

**Бүген һава торышы нинди?** Какая сегодня погода?

Бүген көн жылы.
Бүген көн болытлы.
Бүген көн кояшлы.
Бүген көн эссе.
Бүген көн аяз.
Бүген көн салкын, карлы.

**жылы – теплый**
**болытлы – облачный**
**кояшлы – солнечный**
**эссе – жаркий**
**аяз – ясный**
**жилле – ветреный**
**яңгырлы – дождливый**
**салкын – холодный**
**карлы – снежный**

2. **Үрнәк буенча бүгенге һава торышы турында әйтегез.** Расскажите о сегодняшней погоде по образцу.

*Үрнәк:* Бүген көн салкын, кояшлы һәм аяз. Бүген биш градус жылы.



**3. Диалогларны тыңлагыз һәм укыгыз.** Прослушайте диалоги и прочитайте.

— Алсу, кичә көн нинди иде?

— Кичә унбиш градус җылы иде.

— Көн аяз идеме?

— Юк, болытлы иде.

— Җилле идеме?

— Юк, көн җилле түгел иде.

***

— Сәлам, Марат!

— Сәлам, Айгөл!

— Марат, бүген һава торышы нинди?

— Бүген көн җылы һәм матур.

— Яңгырлымы?

— Юк.

**бүген – сегодня**

**кичә – вчера**

**иртәгә – завтра**

**4. Тыңлагыз һәм укыгыз.** Прослушайте и прочитайте.

**Бүген нинди көн?** Какой сегодня день недели?

**Бүген ничәсе?** Какое сегодня число?

Бүген дүшәмбе, бишенче март.

Кичә якшәмбе, дүртенче март иде.

Иртәгә сишәмбе, алтынчы март.

Шимбә һәм якшәмбе – ял көннәре.

**Атна көннәре. Дни недели**

**дүшәмбе – понедельник**

**сишәмбе – вторник**

**чәршәмбе – среда**

**пәнҗешәмбе – четверг**

**җомга – пятница**

**шимбә – суббота**

**якшәмбе – воскресенье**

**5. Җөмләләрне дәвам итегез.** Продолжите предложения.

Бүген сишәмбе. Көн ... түгел. Хәзер ... градус ... .

Кичә дүшәмбе иде. Көн ... иде.

Иртәгә ... . Иртәгә көн ... була. Бераз ..., ... түгел.

**6. Рәсемнәргә карагыз һәм һава торышы турында әйтегез.** Посмотрите на рисунки и скажите о погоде.






**9. Тыңлагыз һәм укыгыз.** Прослушайте и прочитайте.

**Кайчан?** Когда?

Дүшәмбе көнне 3 градус салкын иде.
Майда көннәр җылы була.
Май аенда көннәр кояшлы.
Бу атнада көннәр яңгырлы.
2012 нче елда март ае болытлы иде.
Кышын көннәр салкын була.
Язын көннәр яңгырлы була.
Җәен көннәр эссе була.
Көзен көннәр болытлы була.

**дүшәмбе көнне – в понедельник**
**ел – год**
**майда – в мае**
**кышын – зимой**
**май аенда – в мае месяце**
**язын – весной**
**көзен – осенью**
**җәен – летом**


Бу – кыш.


Бу – яз.


Бу – җәй.


Бу – көз.

**10. Диалогларны укыгыз.** Прочитайте диалоги.

— Илнур, бүген эссе көн!
— Юк, Айнур, бүген эссе түгел, җылы!
— Шулаймыни?!
— Әйе, май аенда көннәр җилле, җылы, аяз була.

***

— Сәлам, Язгөл!

— Исәнме, Юлдаш!

— Язгөл, кышын көннәр нинди иде?

— Карлы, болытлы, салкын.

— Кайчан җылы була?

— Язын, апрельдә.

***

— Язилә, бу атнада көннәр яңгырлы буламы?

— Әйе, Ясминә, яңгырлы була.

— Дүшәмбе кояшлы түгелме?

— Юк, яңгырлы.

***

— Минемчә, былтыр мартта салкын иде.

— Әйе, көннәр салкын һәм җилле иде.

— Ә быел мартта көннәр нинди?

— Җылы һәм карлы.

**былтыр – в прошлом году**

**быел – в этом году**

**11. Диалогларны тулыландырыгыз.** Дополните диалоги.

— Дустым, дүшәмбе көнне ...?

— Юк, ... .

— Ә көн ... идеме?

— Әйе, ... иде.

***

— Гафу итегез, урамда ... салкын?

— Салкын түгел, ...!

— Ә көн ........?

— Әйе, бераз ... .

**12. Сорауларга җавап бирегез.** Ответьте на вопросы.

Хәзер ничәнче ел? Бүген атнаның кайсы көне? Кичә нинди көн иде? Иртәгә пәнҗешәмбеме? Хәзер нинди ай? Август ничәнче ай? Бүген ничәсе? Бүген утызынчы мартмы?

**13. Дөрес әйтегез.** Скажите правильно.

1 ел = 12 ай = 52 атна = 365/366 көн
1 тәүлек = 24 сәгать
1 сәгать = 60 минут
1 минут = 60 секунд

**тәүлек – сутки**

**14. Тыңлагыз һәм укыгыз.** Прослушайте и прочитайте.

**Бүген көн салкынрак.**
**Язын көннәр җылырак.**
**Көзен көннәр җиллерәк.**
**Быел көннәр эссерәк.**

**Истә калдырыгыз!** Запомните!
*-рак/-рәк* – **сыйфатның чагыштыру дәрәҗәсе кушымчалары** (аффиксы сравнительной степени прилагательных)
җылы – җылы**рак** (теплее); эссе – эссе**рәк** (жарче), салкын-салкын**рак** (холоднее).

**15. Диалогларны укыгыз.** Прочитайте диалоги.

— Гафу итегез, бүген көн салкынракмы?
— Юк, җылырак.
— Рәхмәт.
***
— Гүзәл, кичә көн җилле идеме?
— Юк, бүген җиллерәк һәм салкынрак.
— Шулаймыни?
— Әйе.

— Фәния ханым, бүген көн яңгырлымы?
— Әйе, яңгырлы һәм салкынрак.
— Рәхмәт.
***
— Алия, бу яфраклар нинди?
— Сап-сары.
— Тегеләре дә сарымы?
— Юк, яшелрәк.

**16. Диалогларны тулыландырыгыз.** Дополните диалоги.

— Дустым, хәзер ...?
— ... .

***
— Әби, бүген көн ...?
— Юк, ... .

***

— Апа, дүшәмбе көнне ...?

— Әйе, ... иде.

***

— Булат, Казанда ...?

— Юк, һава торышы ... .

**Истә калдырыгыз!** Запомните!

**Иң эссе** (самый жаркий), **бик жылы** – (очень теплый), **ап-ак** (белый-пребелый) – **сыйфатларның артыклык дәрәҗәсе формалары** (формы превосходной степени прилагательных)

**17. Тыңлагыз һәм укыгыз.** Прослушайте и прочитайте.

Бүген җомга. Бүген көн бик эссе.

Шимбә һәм якшәмбе – ял көннәре. Ял көннәре бик жылы иде.

Кичә көн бик салкын иде.

Татарстанда гыйнвар – иң салкын ай.

Кышын көннәр бик салкын, кар ап-ак.

Җәен агачлар ямь-яшел була.

Көзен яфраклар сап-сары!

Бүген күк зәп-зәңгәр!

**агач – дерево**

**ямь-яшел – зеленый-презеленый**

**яфраклар – листья**

**сап-сары – желтый-прежелтый**

**күк – небо**

**зәп-зәңгәр – голубой-преголубой**

**кып-кызыл – красный-прекрасный**

**18. Җөмләләрне дәвам итегез.** Продолжите предложения.

Кышын көннәр ... . Язын көннәр ... . Җәен көннәр ... . Көзен көннәр... . Татарстанда иң эссе ай – ... . Татарстанда иң салкын ай – ... . Көзен яфраклар ... . Бу яфраклар ... .

**19. Сорауларга җавап бирегез.** Ответьте на вопросы.

Кичә көн яңгырлы идеме? Бүген һава торышы нинди? Хәзер ничә градус жылы? Бүген көн аязмы? Дүшәмбе көнне җиллерәк идеме? Татарстанда көннәр кайчан бик салкын була? Иң эссе көннәр кайчан була?

**20. Мәкальләрне укыгыз һәм истә калдырыгыз.** Прочитайте и запомните пословицы.
*Язның бер көне ел туйдыра.
(Один день весны год кормит.)
*Кышкы кар – көзге икмәк.
(Зимний снег – осенний хлеб.)

**21. Кичәге һава торышы турында әйтегез.** Расскажите о вчерашней погоде.
Кичә ... иде. Көн ... , ..... иде. ... градус ... иде.

**22. Татарча әйтегез.** Скажите по-татарски.
Какая сегодня погода? Сегодня ясный солнечный день. Вчера был дождливый день. Сегодня теплее.

**23. Дөрес әйтегез.** Скажите правильно.

Ю - [йү] – юкә, бию
[йу] – юл, аю

я - [йә] – яшь, яшел
[йа] – яңа, яз

**24. Дөрес языгыз.** Напишите правильно.
*Ю ю* ________________________________
*Я я* ________________________________

**25. Саннарны сүзләр белән языгыз.** Напишите числа словами.
30 ____________________ 40 ____________________
33 ____________________ 44 ____________________

☑ **ҮЗ-ҮЗЕГЕЗНЕ ТИКШЕРЕГЕЗ!** ПРОВЕРЬТЕ СЕБЯ!

**1. Дөрес җавапны табыгыз.** Найдите правильный ответ.
Бүген дүшәмбе, кичә ... иде.
1) сишәмбе 2) якшәмбе 3) җомга
Бүген болытлы ... көн.
1) яңгырлы 2) аяз 3) кояшлы
Хәзер ... ае.
1) май 2) шимбә 3) ике мең уникенче

... сишәмбе иде.

1) бүген 2) иртәгә 3) кичә

Шимбә һәм якшәмбе – ... көннәре.

1) ял 2) март 3) эш

Кичә җылы иде, ә бүген ... .

1) җылырак 2) иртәгә 3) аяз

Май – ... матур ай.

1) бу 2) иң 3) ул

2. **Дөрес тәрҗемәне табыгыз.** Найдите правильный перевод.

**аяз**

1) пасмурный 2) ясный 3) теплый

**иң салкын**

1) холодный 2) очень холодный 3) самый холодный

**дүшәмбе**

1) вторник 2) среда 3) понедельник

**шимбә**

1) четверг 2) суббота 3) пятница

**кояшлырак**

1) солнечнее 2) самый солнечный 3) солнечный

**3. Коммуникатив биремнәрне языгыз.** Напишите коммуникативные задания.

1) Спросите у друга (подруги), какой сегодня день недели.
2) Скажите, что сегодня дождливый день.
3) Уточните у друга (подруги), какая сегодня погода.
4) Как скажете о том, что вчера была ясная погода?
5) Спросите у брата, какой сейчас месяц.
6) Спросите у сестры, какой месяц в году самый теплый.
7) Поинтересуйтесь у бабушки, какой день недели был вчера.
8) Скажите, что завтра будет пасмурно, но тепло.
9) Скажите, что сегодня теплее.
10) Сообщите друзьям, что в Татарстане сейчас 20 градусов тепла.



## **ЕЛ ФАСЫЛЛАРЫ**. ВРЕМЕНА ГОДА

**1. Тыңлагыз һәм укыгыз.** Прослушайте и прочитайте.

**Кайсы ел фасылы?** Какое время года?

Хәзер яз.
Хәзер җәй.
Хәзер көз.
Хәзер кыш.
Дүрт ел фасылы бар: кыш, яз, җәй, көз.

**яз – весна**

**җәй – лето**

**көз – осень**

**кыш – зима**






**2. Үрнәк буенча ел фасыллары турында әйтегез.** Скажите о временах года по образцу.

*Үрнәк:* Хәзер яз. Көннәр җылы, кояшлы һәм матур. Төннәр – салкын. Мин язны яратам.

**төн – ночь**

**Истә калдырыгыз!** Запомните!

***Яратырга*** (любить) / ***яратмаска*** (не любить) **фигыленең**

**хәзерге заманда төрләнеше** (спряжение глагола в настоящем времени)

| | |
|---|---|
| Мин яратам/яратмыйм | Без яратабыз/яратмыйбыз |
| Син яратасың/яратмыйсың | Сез яратасыз /яратмыйсыз |
| Ул ярата/яратмый | Алар яраталар/яратмыйлар |

**3. Диалогларны тыңлагыз һәм укыгыз.** Прослушайте диалоги и прочитайте.

— Алсу, жәй айлары нинди айлар?

— Июнь, июль, август.

— Март – кыш аемы?

— Юк, яз ае.

— Син язны яратасыңмы?

— Бик яратам.

**жәй айлары – летние месяцы**

***

**соң – после**

— Кыштан соң кайсы фасыл килә?

— Кыштан соң яз килә.

— Яз нинди ел фасылы?

— Җылы һәм матур.

— Яңгырлымы?

— Әйе, җылы яңгырлы.

**4. Җөмләләрне дәвам итегез.** Продолжите предложения.

Хәзер кыш. Көннәр... . Кышын ... градус ... . Көннәр җилле, ... . Кыштан соң ... . Көннәр ... була. Язын ... градус ... . Яз көне ... була. Яздан соң ... . Көннәр бик ... була. Җәен ... градус ... . Җәен аяз, ... була. Җәйдән соң ... . Көннәр ... була. Салкын .... көннәр күп була. Көздән соң ... .

**5. Сорауларга җавап бирегез.** Ответьте на вопросы.

Кышын көннәр нинди була? Син кышны яратасыңмы?

Язын көннәр нинди? Син язны яратасыңмы?

Җәен көннәр эссеме? Син җәйне яратасыңмы?

Көзен һава торышы нинди? Син көзне яратасыңмы?

**6. Җөмләләрне тулыландырыгыз.** Дополните предложения.

.... көннәр бик матур, эссе була.

... көннәр бик салкын була.

... көннәр яңгырлы була.

... көннәр җылырак, кояшлы була.

**7. Диалогларны укыгыз һәм үрнәк буенча төзегез.** Прочитайте диалоги и составьте по образцу.

— Илнур, бүген көн салкынмы?

— Юк, җылы. Кичә салкынрак иде.

— Шулаймыни?!

— Әйе, хәзер яз! Язын көннәр җылырак була.

***

— Исәнме, Саша!

— Исәнме, Артур!

— Кышын каникулда син кая барасың?

— Әбиемә, Самарага. Ә син?

— Ә мин Парижга, экскурсиягә.

***

— Гафу итегез, Казанда җәй җылы буламы?

— Әйе, бик җылы, эссе була.

**Истә калдырыгыз!** Запомните!

***Булырга*** (быть) **фигыленең билгеле үткән заманда төрләнеше**

(спряжение глагола в прошедшем определённом времени)

| | |
|---|---|
| **Мин булдым / булмадым** | **Без булдык / булмадык** |
| **Син булдың / булмадың** | **Сез булдыгыз / булмадыгыз** |
| **Ул булды / булмады** | **Алар булдылар / булмадылар** |

**8. Диалогларны тулыландырыгыз.** Дополните диалоги.

— Дустым, җәен син кайда ...?

— Мин ... .

— Ә сез кайда ... ?

— Без ... .

***

— Кышын ... градус җылы ...?

— Җылы түгел, ...!

— Ә җилле көннәр ...?

— Әлбәттә, ...

**9. Сорауларга җавап бирегез.** Ответьте на вопросы.

Кышын син кайда булдың? Августта көннәр нинди булды? Якшәмбе көнне һава торышы нинди булды? Кичә җылы булдымы? Җәен сез шәһәрдә булдыгызмы? Шимбә көнне алар кайда булдылар?

**10. Тыңлагыз һәм укыгыз.** Прослушайте и прочитайте.

**Кыш айлары салкын, җилле, карлы булды.**

**Язын көннәр озын, ә төннәр кыска була.**

**Җәен без шәһәрдә булмадык.**

**Көзен яфраклар сап-сары була.**

**кыска – короткий**

**озын – длинный**

**11. Җөмләләрне тулыландырыгыз.** Дополните предложения.

Җәен без ... булмадык. Кичә ул ... булмады. Дүшәмбе көнне алар ... булмадылар. Декабрьдә көннәр ... булмады. Сез мартта ... булдыгызмы? Син ... кайчан булдың?

**12. Сорауларга җавап бирегез.** Ответьте на вопросы.

А) Хәзер нинди ел фасылы? Аннары кайсы ел фасылы килә? Син кайсы ел фасылын яратасың? Бүген һава торышы нинди?

Ә) Дүшәмбе көнне җылы булдымы? Көннәр кайчан бик салкын булды? Җәен Казанда ничә градус җылы була? Язын көннәр аязмы? Кышын көннәр җиллеме? Быел кыш карлы булдымы?

**13. Мәкальләрне укыгыз һәм истә калдырыгыз.** Прочитайте и запомните пословицы.

*Апрель туса, яз була.

(С наступлением апреля весна начинается.)

*Җәй көне чананны, кыш көне арбаңны әзерлә.

(Готовь летом сани, а зимой – телегу.)

**14. Ел фасыллары турында сөйләгез.** Расскажите о временах года.

**15. Сораулар куегыз һәм укыгыз.** Поставьте вопросы и прочитайте.

...? Кышын көннәр карлы булды.

...? Әйе, кичә көн җылырак булды.

...? Без июль аенда Төркиядә булдык.

...? Мин каникулда Кытайда булдым.

...? Былтыр дустым Парижда булды.

**Истә калдырыгыз!** Запомните!

**-ды/-де, -ты/-те – билгеле үткән заман фигыль кушымчалары** (окончания прошедшего определённого времени глагола)

**Ул нишләде? Ул барды** (ходил, ездил), **килде** (пришёл, приехал), **кайтты** (вернулся), **китте** (ушёл, уехал)

**16. Диалогларны укыгыз һәм үрнәк буенча төзегез.** Прочитайте диалоги и составьте по образцу.

— Җәен кая бардыгыз?

— Диңгезгә бардык.

— Кырымгамы?

— Әйе, Кара диңгезгә.

**диңгез – море**

**Кара диңгез – Черное море**

***

— Гүзәл, син кышын кайда ял иттең?

— Әбиләрдә, авылда.

— Күңелле булдымы?

— Бик күңелле.

**авыл – деревня**

***

— Фәния ханым, быел җәй яңгырлы идеме?

— Әйе.

— Көз дә яңгырлы идеме?

— Әйе, көзен дә яңгырлар күп булды!

17. **Диалогларны тулыландырыгыз.** Дополните диалоги.

— Дустым, кичә паркта булдыңмы?
— ... .
— Һава торышы нинди булды?
— ... .

***

— Абыем, кичә син ... бардыңмы?
— Юк, ... .

— Җәен син ... ял иттең?
— ... булдым.

***

— Гафу ит, Булат, ...?
— ... бардым.

18. **Татарча әйтегез.** Скажите по-татарски.

Летом я был в деревне. В июле мы отдыхали на море. Вчера он ходил в парк. В среду они вернулись из Москвы. Сегодня мой друг уехал в Турцию.

19. **Дөрес әйтегез.** Скажите правильно.

б – [б] – бу, бар
бүген, без

п – [п] – пылау, апа
пәнҗешәмбе, ипи

20. **Дөрес языгыз.** Напишите правильно.

*Б б* ____________________________________

*П п* ____________________________________

21. **Саннарны сүзләр белән языгыз.** Напишите числа словами.

50 ________________ 60 ________________

55 ________________ 66 ________________

## ☑ ҮЗ-ҮЗЕГЕЗНЕ ТИКШЕРЕГЕЗ! ПРОВЕРЬТЕ СЕБЯ!

1. **Дөрес җавапны табыгыз.** Найдите правильный ответ.

Җәен көннәр кояш... була.

1) -лы 2) -ле 3) -сез

Көзен көннәр яңгыр... була.

1) -ле 2) -лы 3) -лар

Кышын  көннәр буран... иде.

1) -ле 2) -лы 3) -сез

Язын җылы... була.

1) -лы 2) -сыз 3) -рак

Март, апрель, май – яз ай.....

1) -ләре 2) -е 3) -лары

Март – яз... беренче ае.

1) -ның 2) -нең 3) -ын

Җәен көн... бик эссе.

1) -ләр 2) -нар 3) -нәр

2. **Дөрес тәрҗемәне табыгыз.** Найдите правильный перевод.

**язын**

1) весна 2) ясный 3) весной

**көзен**

1) осенью 2) осень 3) зимой

**кышын**

1) зима 2) осень 3) зимой

**булдык**

1) вы были 2) я была 3) мы были

**булдың**

1) ты был 2) он был 3) они были

**3. Коммуникатив биремнәрне языгыз.** Напишите коммуникативные задания.

1) Спросите у друга (подруги), какое сейчас время года.
2) Скажите, что сейчас месяц май.
3) Уточните у друга (подруги), какое время года он (она) любит.
4) Как скажете о том, что зимой на каникулах вы были в Турции?
5) Спросите у брата, какой по счету месяц сентябрь.
6) Спросите у сестры, куда она ездила летом.
7) Поинтересуйтесь у бабушки, любит ли она лето.
8) Скажите, что завтра первый день весны.
9) Скажите, что сегодня жаркий ясный летний день.
10) Сообщите друзьям, что в воскресенье вы были в музее.



## БӘЙРӘМНӘР. ПРАЗДНИКИ

**1. Тыңлагыз һәм укыгыз.** Прослушайте и прочитайте.

**Нинди бәйрәмнәр була?** Какие праздники бывают?

Кышын Яңа ел бәйрәме була.

7 нче гыйнвар – Раштуа бәйрәме.

8 нче Март – Хатын-кызлар бәйрәме.

23 нче февраль – Ватанны саклаучылар көне.

Җәен Сабан туе була.

Туган көнем 15 нче мартта.

**Яңа ел – Новый год**

**Раштуа – Рождество**

**Ватанны саклаучылар көне – День защитников Отечества**

**Хатын-кызлар көне – праздник женщин**

**Сабан туе – праздник Сабантуй**

**туган көнем – мой день рождения**

**2. Диалогларны укыгыз һәм үрнәк буенча төзегез.** Прочитайте диалоги и составьте по образцу.

— Гафу итегез, кышын нинди бәйрәмнәр була?

— Яңа ел, Раштуа бәйрәме, Ватанны саклаучылар көне.

— Яңа елда сез кайда булдыгыз?
— Без туганнарыбызда булдык.
***
— Туган көнең кайчан булды?
— 15 нче мартта.
— Туган көнеңә кемнәр килде?
— Дусларым, туганнарым.
***
— Вәсилә, туган көнегез кайчан?
— 12 нче апрельдә.
— Бүгенме?
— Әйе, бүген!
— Котлыйм!
— Рәхмәт!

***
— Вәли, сездә Сабан туе кайчан була?
— Җәен.
— Кайсы айда? Августтамы?
— Юк, июньнең беренче атнасында.
— Рәхмәт.

**котларга – поздравить**

**3. Җөмләләрне дәвам итегез.** Продолжите предложения.
Сабаен туе майда түгел, ... . Туган көнем .... . Яңа ел бәйрәмендә ... .
7 нче гыйнварда ... . Әниләр бәйрәме ... . 8 нче март – ... . 23 нче февраль – ... .

**4. Сорауларга җавап бирегез.** Ответьте на вопросы.
Синең туган көнең кайчан? Туган көнеңдә кемнәр була? Туган көнеңне кайда бәйрәм итәсең? Дустыңның туган көне кайчан?

**уңыш – успех**

**5. Тыңлагыз һәм укыгыз.** Прослушайте и прочитайте.
Кичә Яңа ел бәйрәме булды. Без бер-беребезне бәйрәм белән котладык. Әти-әнием, дусларым миңа күп бүләкләр бирделәр. Мин дә аларны Яңа ел белән котладым. Аларга сәламәтлек, шатлык, уңышлар, мәхәббәт теләдем, бүләкләр бирдем. Яңа ел бәйрәме күңелле үтте.

**бүләк – подарок**
**бер-беребезне – друг друга**
**үтәргә – проходить**
**сәламәтлек – здоровье**
**шатлык – радость**
**мәхәббәт – любовь**
**теләргә – пожелать**

**6. Укыгыз һәм истә калдырыгыз.** Прочитайте и запомните.

**Мин** сезне бәйрәм белән котлыйм.

**Минем** туган көнем унберенче марта.

**Миңа** кунакка барырга кирәк.

Бәйрәмдә дусларым **мине** котладылар.

Дустым **миннән** китап алды.

**Миндә** аның адресы бар.

МИН

***

**Ул** бәйрәмгә бара.

**Аның** бүген туган көне.

**Аңа** күп бүләкләр бирделәр.

Син **аны** Яңа елда күрдеңме?

Бу бүләкләр **аңардан**мы?

**Аңарда** татарча китаплар күп.

УЛ

**7. Сораулар куегыз һәм укыгыз.** Поставьте вопросы и прочитайте.

...? Мин туганнарыбызга бәйрәмгә килдем.

...? Без аны бәйрәм белән котладык.

...? Дустым миңа бүләк бирде.

...? Алар сиңа сәлам әйттеләр.

...? Ул миңа сорау бирде.

...? Без аларга кунакка бардык.

**Истә калдырыгыз!** Запомните!

***белән*** (с, на), ***өчен*** (для, ради), ***турында*** (о, об), ***соң*** (после) – **бәйлекләр** (послелоги)

**бәйрәм белән** (с праздником); **дустым өчен** (для моего друга), **әнием турында** (о моей маме), **яздан соң** (после весны)

**8. Сүзләрне кирәкле формада куегыз һәм укыгыз.** Поставьте слова в нужной форме и прочитайте.

Яңа елда (мин) ... бүләкләр бирделәр. Апам (без) ... бәйрәм белән котлады. Ул (без) ... бәхет, шатлык, сәламәтлек теләде. Без дә (ул)... бәйрәм белән котладык, (ул) уңышлар теләдек. Мин (апам) сәламәтлек теләдем. Дусларым,(сез) бәйрәм белән котлыйм! Мин бу (бүләк) дустым өчен алдым. (Яз) соң җәй килә. Мин (җәй) яратам.

**9. Сорауларга җавап бирегез.** Ответьте на вопросы.

Син бәйрәмдә кая бардың? Сез дустыгызга нәрсә бүләк иттегез? Якшәмбедә сезгә кунаклар килдеме? Алар синең туган көнеңә килделәрме? Дусларыгыз сезгә нинди теләкләр теләделәр? Сезне кемнәр бәйрәм белән котлады? Сезгә нәрсәләр бүләк иттеләр?

**10. Җөмләләрне тулыландырыгыз.** Дополните предложения.

Мин кичә ... бардым. Без Сабан туенда ... . Дустымның туган көне – ... . Дусларымны бәйрәм белән ... . Мин апама ... теләдем. Дәрестә без ... котладык. Алар миңа ... теләделәр.

**11. Тыңлагыз һәм укыгыз.**

**Прослушайте и прочитайте.**

**Бу бәйрәм күңелле, ә теге бәйрәм күңеллерәк булды.**

**Шул көнне без дискотекага бардык.**

**Әнә анда бүләкләр, менә монда котлаулар.**

**Анда – дусларым, ә монда туганнарым бар.**

**Әнә теге кеше кем?**

**Әнә анда нәрсә бар?**

**котлау – поздравление**

**Бәйрәм белән!**

***

**Яңа ел белән!**

***

**Туган көнегез белән котлыйм!**

***

**Сезгә сәламәтлек, уңышлар, бәхет телим!**

**Истә калдырыгыз!** Запомните!

***Бу*** *(это/этот/эта)*, ***теге*** *(то/тот/та)*, ***шул*** *(то/тот/та)*, ***әнә*** *(вот)*, ***менә*** *(вот)*, ***монда*** *(тут)*, ***тегендә*** *(там)* –

**күрсәтү алмашлыклары** (указательные местоимения)

**Бу** бәйрәм (этот праздник), **теге ел** (тот год), **шул** көн (тот день), әнә **бүләк** (вот подарок), **менә яз** (вот весна).

**12. Диалогларны укыгыз.** Прочитайте диалоги.

— Гафу итегез, бәйрәм монда буламы?

— Әйе, менә монда. Рәхим итегез.

— Рәхмәт.

***

— Дания ханым, бүген сездә бәйрәм буламы?

— Әйе.

— Кайда була?

— Теге бинада.

— Яхшы булсын!

— Рәхмәт!

**бина – здание**

**13. Диалогларны тулыландырыгыз.** Дополните диалоги.

— Исәнмесез, хәзер ... була?

— ... .

— Безгә керергә ярыймы?

— ... .

— Гафу итегез, ... әфәнде – Булатмы?

— Юк, ... түгел, ... .

— Рәхмәт.

**14. Рәсемнәргә карагыз һәм сүзләрне истә калдырыгыз.** Посмотрите на рисунки и запомните слова.

Кайда?



**Менә монда** чәчәкләр.




**Әнә тегендә** китап.



**Әнә** Яңа ел бәйрәме.




**Менә** Сабан туе.

**15. Сорауларга җавап бирегез.** Ответьте на вопросы.

Син кая бардың? Син кайсы бәйрәмнән кайттың? Син кайда булдың? Син нинди бүләкләр алдың? Син кемне котладың?

**16. Рәсемнәргә карагыз һәм сорауга җавап бирегез.** Посмотрите на рисунки и ответьте на вопрос.

Бу нинди бәйрәм?












**17. Укыгыз һәм яраткан бәйрәмегез турында сөйләгез.** Прочитайте и расскажите о своем любимом празднике.

Мин бәйрәмнәрне бик яратам. Кышын Яңа ел бәйрәме була. Без дусларга, туганнарга бүләкләр бирәбез, матур сүзләр әйтәбез.

Язын 8 нче Март бәйрәме була. Хатын-кызларны ир-атлар бәйрәм белән котлыйлар, чәчәкләр бүләк итәләр.

Җәен Татарстанда Сабан туе була. Без авылга кайтабыз. Туганнарыбыз белән бәйрәм итәбез.

Көзен минем туган көнем була. Туганнарым, дусларым мине бәйрәм белән котлыйлар, бүләкләр бирәләр.

**хатын-кыз – женщина**

**ир-ат – мужчина**

**18. Шигырьне тыңлагыз һәм сәнгатьле итеп укыгыз.** Прослушайте и прочитайте выразительно стихотворение.

**Әниләр бәйрәме**

Кояш көлә, мин елмаям,
8 нче март бүген.
Бүген әниләр бәйрәме,
Шуңа күңелем шат минем.

— Бәйрәм бүген, бәйрәм! – диеп,
Бар дөнья көлеп торсын.
Әни бәйрәме икәнен
Әти дә белеп торсын,
Әти дә көлеп торсын!

*Сажидә Сөләйманова*

**19. Мәкальләрне укыгыз һәм истә калдырыгыз.** Прочитайте пословицы и запомните.

*Көн дә бәйрәм, көн дә туй.
(Каждый день праздник, каждый день свадьба.)
*Көн дә бәйрәм булмый.
(Не каждый день праздник.)

**20. Дөрес әйтегез.** Скажите правильно.

в – [w] – вакыт, Вәли
[в] – ваза, вертолёт

ф – [ф] – фасыл, Фәнил

**21. Дөрес языгыз.** Напишите правильно.

*В в* ________________________________

*Ф ф* ________________________________

**22. Саннарны сүзләр белән языгыз.** Напишите числа словами.

70 ____________________ 80 ____________________

77 ____________________ 88 ____________________

## ☑ ҮЗ-ҮЗЕГЕЗНЕ ТИКШЕРЕГЕЗ! ПРОВЕРЬТЕ СЕБЯ!

1. **Дөрес җавапны табыгыз.** Найдите правильный ответ.

Кичә дустым Сабан туенда ....

1) була 2) булырга 3) булды

Яңа ел бәйрәме ... була.

1) кыш 2) кышын 3) кышкы

Алар туган көнем белән ... котладылар.

1) мин 2) миңа 3) мине

Бу ханым Яңа елда Мәскәүдә ... .

1) булдым 2) булды 3) булдык

Теге әфәнде... бүләкләр бирдек.

1) -гә 2) -не 3) -нең

Укытучыбызны туган көн... белән котладык.

1) -е 2) -гә 3) -дә

Бәйрәм... дусларыбыз килделәр.

1) -гә 2) -кә 3) -тән

Кышын бәйрәм... күп.

1) -лар 2) -лər 3) -нәр

2. **Дөрес җавапны табыгыз.** Найдите правильный ответ.

**бәйрәм**

1) подарок 2) праздник 3) пожелание

**шатлык**

1) счастье 2) успех 3) радость

**теләргә**

1) разговаривать 2) желать 3) учить

**монда**

1) там 2) здесь 3) этот

**бу**

1) тот 2) такой 3) это

**шул**

1) этот 2) тот 3) там

**3. Коммуникатив биремнәрне языгыз.** Напишите коммуникативные задания.

1) Скажите, когда у Вас день рождения.
2) Спросите одноклассника, где он был в Новый год.
3) Уточните у друга (подруги), какие праздники он (она) любит.
4) Как скажете о том, что у вашей сестры день рождения весной?
5) Пожелайте учителю здоровья, успехов.
6) Скажите, что вы делали на празднике.
7) Как скажете о том, что Вам нужно пойти к другу на день рождения?
8) Скажите, что ваши друзья сейчас здесь.
9) Скажите, что их подарки там.
10) Скажите, что вы рассказали монолог о праздниках.




КӨНДӘЛЕК. РЕЖИМ ДНЯ

1. **Диалогларны укыгыз.** Прочитайте диалоги.

— Сез бүген сәгать ничәдә йокыдан тордыгыз?
— Сәгать җидедә.
— Ял көннәрендә сәгать ничәдә торасыз?
— Сәгать унда.

***

— Гафу итегез, Сез сәгать ничәдә эшкә китәсез?
— Сәгать сигездә.
— Кичен ничәдә кайтасыз?
— Алтыда.

***

— Дустым, иртән син нишләдең?
— Юындым, киендем, иртәнге ашны ашадым.
— Иртәнге ашны кем әзерләде?
— Мин әзерләдем!

**йокыдан торырга – вставать**

**иртәнге аш – завтрак**

**әзерләргә – приготовить**

**ашарга – кушать**

**пешерергә – варить, готовить, печь**

**иртән (иртә белән) – утром**

**киенергә – одеваться**

**юынырга – умываться**

***

— Гүзәл, көндез очрашабызмы?

— Ярар.

— Кая барабыз?

— Кафега.

**көндез – днем**

**кичен (кич белән) – вечером**

**очрашырга – встречаться**

**2. Рәсемнәргә карагыз һәм сорауларга җавап бирегез.** Посмотрите на рисунки и ответьте на вопросы.



Бу малай сәгать ничәдә йокыдан тора?



Бу кыз нишли?



Бу апа кая бара?




Бу абый кайдан кайта?

**3. Җөмләләрне тулыландырыгыз.** Дополните предложения.

Мин ... йокыдан торам. Ул ... эшкә бара. Алар ... иртәнге ашны ашыйлар. Без ... өйгә кайтабыз. Бу кызлар ... ашыйлар. Бу кешеләр ... эштән кайталар.

**4. Тыңлагыз һәм укыгыз.** Прослушайте и прочитайте.

**Мин иртән сәгать җидедә торам. Мин юынам, киенәм.**

**Аннары мин иртәнге ашны ашыйм. Сәгать сигездә мин мәктәпкә китәм.**

**Дәресләрем тугызынчы яртыда башлана.**

**5. Җөмләләрне дәвам итегез.** Продолжите предложения.

Мин якшәмбе көнне эшкә бармыйм,... . Ул иртән тора, ... . Без кичен телевизор ... . Алар якшәмбе көнне ... . Дустым шимбә көнне ... . Әбием иртәнге аш ... .

**6. Укыгыз һәм сөйләгез.** Прочитайте и расскажите.

**Көндәлек режим.** Режим дня

Мин иртә белән сәгать җидедә йокыдан торам. Юынам, киенәм, иртәнге ашны ашыйм һәм укырга китәм. Дәресләрем сәгать тугызынчы яртыда башлана. Һәр көн 4–5 дәрес була. Сәгать уникедә мин ашханәдә көндезге ашны ашыйм. Дәресләр сәгать бердә-икедә бетә. Аннары мин өйгә кайтам.

Өйдә ял итәм, әти-әнигә булышам, телевизор карыйм, өй эшләрен эшлим. Кичен без дуслар белән очрашабыз, кинога, бассейнга барабыз.

Ял көннәрендә мин сәгать унда торам. Көндез өйдә булам. Кичләрен дусларым белән кафега, клубка барырга яратам.

**көндезге аш – обед**

**ял итәргә – отдыхать**

**булышырга – помогать**

**7. Укыгыз.** Прочитайте.

Иртәнге ашка кадәр әбием белән телефоннан сөйләштем.

Эшкә кадәр ул газеталар укый. Ул көн саен сәгать алтыда тора.

Без бәйрәм саен әбиләргә барабыз.

**Истә калдырыгыз!** Запомните!

***Кадәр*** *(до)*, ***саен*** *(каждый)* – **бәйлекләр** (послелоги)

Өйгә **кадәр** (до дома), иртәнге аш**ка кадәр** (до завтрака), эш**кә кадәр** (до работы), дәрес **саен** (на каждом уроке), көн **саен** (каждый день), бәйрәм **саен** (каждый праздник).

**8. Рәсемнәргә карагыз һәм сорауларга җавап бирегез.** Посмотрите на рисунки и ответьте на вопросы.



Алсу кем белән аш пешерә?



Әни кем өчен иртәнге аш әзерли?



Эштән соң әти нишли?



Сериалга кадәр әни нишли?

**Истә калдырыгыз!** Запомните!

***Торырга*** (вставать) / ***тормаска*** (не вставать) **фигыленең билгеле үткән заманда төрләнеше** (спряжение глагола в прошедшем определённом времени)

| | |
|---|---|
| **Мин тордым/тормадым** | **Без тордык/тормадык** |
| **Син тордың/тормадың** | **Сез тордыгыз /тормадыгыз** |
| **Ул торды/тормады** | **Алар тордылар/тормадылар** |

**9. Укыгыз һәм үрнәк буенча әйтегез.** Прочитайте и скажите по образцу.

Иртән сәгать алтыда йокыдан тордым.
Юындым, киендем, ашадым һәм эшкә киттем.
Эшкә сәгать сигездә килдем.
Сәгать уникедә көндезге ашны ашадым.
Сәгать биштә эштән кайттым.
Кичен ял иттем, телевизор карадым, кичке ашны ашадым.
Сәгать унбердә йокларга яттым.

**йокларга ятарга – лечь спать**

**10. Җөмләләрне тулыландырыгыз.** Дополните предложения.

... йокыдан торам . ... эшкә китәм . ... эшлим . ... өйгә кайтам. ... телефоннан сөйләшәм. ... очрашам. ... ял итәм.

**11. Сорауларга җавап бирегез.** Ответьте на вопросы.

Син сәгать ничәдә йокыдан торасың? Син иртәнге ашка нәрсә ашыйсың? Син эшкә ничә минут барасың? Эштән соң син нишлисең? Син кем белән ял итәсең? Син кайда ял итәсең?

**12. Сораулар куегыз һәм укыгыз.** Поставьте вопросы и прочитайте.
...? Иртәнге аштан соң эшкә китәм.
...? Кичке ашка кадәр кибеткә барам.
...? Без дуслар белән якшәмбе саен очрашабыз.
...? Дустым белән ял көннәре турында сөйләшәбез.

**Истә калдырыгыз!** Запомните!
***Ашарга*** (кушать) / ***ашамаска*** (не кушать) **фигыленең билгеле үткән заманда төрләнеше**
(спряжение глагола в прошедшем определенном времени)

| | |
|---|---|
| **Мин ашадым / ашамадым** | **Без ашадык / ашамадык** |
| **Син ашадың / ашамадың** | **Сез ашадыгыз / ашамадыгыз** |
| **Ул ашады / ашамады** | **Алар ашадылар / ашамадылар** |

**13. Җөмләләрне дәвам итегез.** Продолжите предложения.
Сез бүген иртән нәрсә ...? Алар кичен нәрсә ...? Кунаклар кафеда ...? Син иртән сәгать ничәдә ...? Ул пицца ...? Алар көндез кайда ...?

**14. Үрнәк буенча иртәнге аш турында әйтегез.** Скажите по образцу о завтраке.
*Үрнәк:* Мин иртәнге ашны сәгать сигезенче яртыда ашыйм. Бүген мин сыр белән күмәч ашадым. Чәй эчтем.

**15. Сорауларга җавап бирегез.** Ответьте на вопросы.
Иртән сез нишлисез? Иртәнге аштан соң кая барасыз?
Көндез сез нишлисез? Көндезге ашны кайда ашыйсыз?
Кичен сез нишлисез? Кичке аштан соң кем белән аралашасыз?

**16. Дустыгызга шалтыратыгыз һәм аның көндәлек режимы турында сорагыз.** Позвоните другу и спросите о его режиме дня.

**17. Сүзләр белән җөмләләр төзегез.** Составьте предложения с данными словами.
Иртән, көндез, кичен, торырга, юынырга, ашарга, барырга, кайтырга, ял итәргә.

**18. Текстны тулыландырыгыз.** Дополните текст.

Мин иртә белән сәгать ... йокыдан торам. Юынам, киенәм, иртәнге ашны ашыйм һәм ... китәм. ... сәгать ... башлана. Көн саен мин ... . Сәгать ... мин көндезге ашны ашыйм. ... сәгать ... бетә. Аннары мин ... . Өйдә ял итәм, ... . Кичен без дуслар белән ... барабыз. Ял көннәрендә мин сәгать ... торам. Көндез ... . Кичләрен ... .

**19. Дөрес әйтегез.** Скажите правильно.

г – [ғ] – гомер, агач

[г] – гөл, Гүзәл

к –[қ] – кунак, калак

[к] – кич, китап

**20. Дөрес языгыз.** Напишите правильно.

*Г г* ____________________

*К к* ____________________

**21. Саннарны сүзләр белән языгыз.** Напишите числа словами.

90 __________ 100 __________

99 __________ 111 __________

☑ **ҮЗ-ҮЗЕГЕЗНЕ ТИКШЕРЕГЕЗ!** ПРОВЕРЬТЕ СЕБЯ!

1. **Дөрес җавапны табыгыз.** Найдите правильный ответ.

Дустым сәгать алтыда йокы... тора.

1) -тән 2) -тан 3) -дан

Иртәнге аш... соң эшкә китәм.

1) -ка 2) -тән 3) -тан

Бу кыз Чехов урамы... эшкә бара.

1) -ндә 2) -на 3) -нда

Төшке аш... кадәр офиста эшлим.

1) -та 2) -тан 3) -ка

Көн саен дусларым белән телефон... сөйләшәм.

1) -нан 2) -да 3) -нда

Без кинога, кафе... барырга яратабыз.

1) -да 2) -га 3) -гә

Мин эштән өй.... кайтам.

1) -гә 2) -да 3) -дә

Без кичен дусларыбызга бар... .

1) -ырга 2) -абыз 3) -дылар

2. **Дөрес тәрҗемәне табыгыз.** Найдите правильный перевод.

**иртәнге аш**

1) обед 2) завтрак 3) ужин

**юынырга**

1) умываться 2) одеваться 3) собираться

**эштән соң**

1) до работы 2) после работы 3) о работе

**турында**

1) с 2) для 3) о/об

**ял итәргә**

1) отдыхать 2) одеваться 3) готовить

**иртән**

1) утро 2) завтра 3) утром

3. **Коммуникатив биремнәрне языгыз.** Напишите коммуникативные задания.

1) Спросите друга (подругу), во сколько он (она) встает.
2) Уточните у друга (подруги), что он делает после завтрака.
3) Скажите, в котором часу вы идете на работу (на учёбу).
4) Поинтересуйтесь у бабушки, для кого она готовит ужин.
5) Позвоните другу и спросите, что он делал сегодня.
6) Как скажете о том, что вы в выходные идёте на футбол?
7) Спросите, что делает ваш брат каждый день.
8) Скажите, что сегодня в обед вы сходили в кафе.
9) Как скажете о том, что вы любите смотреть сериалы?
10) Уточните, во сколько он ложится спать.



## СӘЛАМӘТЛЕК. ЗДОРОВЬЕ

**1. Тыңлагыз һәм укыгыз.** Прослушайте и прочитайте.

**Сәламәтлегегез ничек?** Как ваше здоровье?

— Син исән-саумы?

— Рәхмәт, мин сау-сәламәт.

***

— Дустың авырыймы?

— Әйе, ул хастаханәдә ята.

**исән-сау – жив(а)-здоров(а)**

**сау-сәламәт (сәламәт) – здоров(а)**

**хастаханә – больница**

**авыру – больной; болезнь**

**авырырга – болеть**

**ятарга – лежать**

**Истә калдырыгыз!** Запомните!

***авырырга*** (болеть) / ***авырмаска*** (не болеть) **фигыленең билгеле үткән заманда төрләнеше**

(спряжение глагола в прошедшем определённом времени)

| | |
|---|---|
| Мин авырдым / авырмадым | Без авырдык / авырмадык |
| Син авырдың / авырмадың | Сез авырдыгыз / авырмадыгыз |
| Ул авырды / авырмады | Алар авырдылар / авырмадылар |

**2. Диалогларны укыгыз һәм үрнәк буенча төзегез.** Прочитайте диалоги и составьте по образцу.

— Кичә ни өчен дәрестә булмадың?
— Мин авырдым.
— Хастаханәгә бардыңмы?
— Әйе, бардым.

***

— Дамир, әниең исән-саумы?
— Хәзер исән-сау. Ике атна элек авырды.
— Хастаханәгә бардымы?
— Әйе. Ун көн хастаханәдә ятты.
— Табиблар ярдәм иттеме?
— Әйе, рәхмәт аларга.

***

— Таһир, хәлләрең ничек?
— Башым авырта.
— Дару эчтеңме?
— Юк. Нинди дару эчәргә кирәк?
— Цитрамон.

***

— Әбием, кайсы җирең авырта?
— Аякларым авырта, улым.
— Табиб чакырырга кирәкме?
— Әйе. Рәхмәт, балам.

**Ни өчен? – почему?**

**элек – раньше**

**авырта – болит**

**дару – лекарство**

**чакырырга – позвать, вызывать**

**кайсы җирең авырта? – что болит?**



**3. Җөмләләрне дәвам итегез.** Продолжите предложения.

Мин исән-сау, ә әнием ... .
Дустымның башы ... .
Дамирның күзләре ... .
Таһирның кулы авыртмый, аягы ... .
Бу әфәнде хастаханәдә ..., ул - ... .
Әбиемнең колаклары ... .
Шакирның тамагы ....

**баш – голова**
**күз – глаз**
**аяк – нога**
**кул – рука**
**колак – ухо**
**тамак – горло**

**4. Сорауларга җавап бирегез.** Ответьте на вопросы.

Сез сәламәт кешеме? Сез авырмыйсызмы? Бүген башыгыз авыртмыймы?
Дустыгыз исән-саумы? Ул хастаханәдә ятмадымы? Аның кулы авыртмыймы?

**5. Җөмләләрне тулыландырыгыз.** Дополните предложения.

Дүшәмбе көнне һәм сишәмбе көнне мин ... бармадым. Мин ике көн ... . Минем башым ... . Аннары мин хастаханәгә ... . Табиб миңа ... бирде. Хәзер мин ... . Иртәгә .... барам.

**6. Тыңлагыз һәм укыгыз.** Прослушайте и прочитайте.

— Мин авырыйм, өйгә табиб чакыр.
— Дустым, сәламәт бул!
— Дустым, авырма!
— Әби, даруыңны эч!
— Кулларың, аякларың сызламасын!
— Укучылар, җәен, кышын чыныгыгыз!
— Дуслар, сәламәтлек турында уйлагыз!

**сәламәт булырга – быть здоровым**
**сызларга – ныть**
**чыныгырга – закаляться**
**уйларга – думать**

**Истә калдырыгыз!** Запомните!

**Сәламәт бул!** (Будь здоров!); **Сәламәт булыгыз!** (Будьте здоровы!);
**Чынык** (Закаляйся!); **Чыныгыгыз!** (Закаляйтесь!);
**Әйт!** (Скажи!); **Әйтегез!** (Скажите!) –
**боерык фигыльләр** (глаголы повелительного наклонения)

| | |
|---|---|
| **Син әйт/әйтмә** | **Сез әйтегез/әйтмәгез** |
| **Ул әйтсен/әйтмәсен** | **Алар әйтсеннәр/әйтмәсеннәр** |

**7. Җөмләләрне тулыландырыгыз.** Дополните предложения.

Әбием, сәламәт ... !

Сезне бәйрәм белән ... !

Ул кышын ... !

Алар кибеткә ... !

**8. Сорауларга җавап бирегез.** Ответьте на вопросы.

Син кайчан чыныгасың? Син кышын ничек чыныгасың? Сез җәен чыныгасызмы? Сез җәен ничек чыныгасыз? Ул кемгә бу сүзләрне әйтсен? Ул дустына нәрсә турында әйтмәсен?

**Истә калдырыгыз!** Запомните!

**Әйт әле (әйтче)** (скажи, пожалуйста), **әйтегез әле (әйтегезче)** (скажите, пожалуйста); **кил әле (килче)** (приходи, пожалуйста), **килегез әле (килегезче)** (приходите, пожалуйста); **эч әле (эчче)** (пей, пожалуйста), **эчегез әле (эчегезче)** (пейте, пожалуйста); **бар әле (барчы)** (иди, пожалуйста), **барыгыз әле (барыгызчы)** (идите, пожалуйста) **– теләк белдерү формалары** (формы выражения просьбы).

**9. Җөмләләрне укыгыз.** Прочитайте предложения.

Дустым, уңышларың турында әйт әле. Зөфәр, безгә кил әле. Апам, бу даруны эч әле. Абый, иртәгә табибка бар әле, дарулар алырга рецепт кирәк. Самира, бүген безгә килче, мин авырыйм. Закир, бу сокны эч әле. Сиринә, концертка син барчы, минем башым авырта.

**10. Тыңлагыз һәм укыгыз.** Прослушайте и прочитайте.

**Сәламәт булу өчен, нишләргә кирәк?** Что нужно делать, чтобы быть здоровым?

Сәламәт булу өчен, яшелчәләр аша.

Сәламәт булу өчен, ит һәм сөт ризыклары ашагыз.

Йөгерү өчен, урамга чык.

Сәламәт булу турында китаплар укы.

Саф һавада йөр.

Йөзү белән шөгыльләнү өчен, бассейнга барыгыз.

**яшелчәләр – овощи**

**ит – мясо**

**сөт – молоко**

**ризык – пища, продукты**

**саф һава – свежий воздух**

**йөзү – плавание**

**шөгыльләнергә – заниматься**

**Истә калдырыгыз!** Запомните!

**Булырга – булу** (быть), **ашарга – ашау** (кушать), **эчәргә – эчү** (пить), **йөрергә – йөрү** (ходить) — **исем фигыльләр** (имена действия);

**исем фигыль + бәйлек** (имя действия + послелог):

**булу өчен** (для того, чтобы быть), **ашау турында** (о еде),

**ул килү белән** (как только он приедет).

**11. Сорауларга җавап бирегез.** Ответьте на вопросы.

Сәламәт булу өчен, Сез нишлисез? Сездә дөрес ашау турында китаплар бармы? Сиңа дару эчү өчен, нәрсә кирәк? Дустың йөгерү белән шөгыльләнәме? Саф һавада йөрү өчен, урамга чыгабызмы?

**12. Диалогларны укыгыз.** Прочитайте диалоги.

— Гафу итегез, сәламәт булу өчен, Сез нишлисез?
— Спорт белән шөгыльләнәм.
— Физик күнегүләр ясыйсызмы?
— Әйе, көн саен ясыйм.

— Зилә, дару эчү өчен, су бир әле.
— Ярар. Сиңа нәрсә булды?
— Башым авырта.

**13. Диалогларны тулыландырыгыз.** Дополните диалоги.

**физик күнегүләр – физические упражнения**

— Исәнмесез, кәефегез ...?
— Башым ... .
— Дару ...?
— Юк. Дару эчү өчен ...  кирәк.

***

— Гафу итегез, Сания апа, урманга ... өчен, рюкзак кирәк. Сездә бармы?
— ... . Урманга .... барасыз?
— Бүген ... .

**урман – лес**

**14. Сораулар куегыз.** Поставьте вопросы.

....? Сәламәт булу өчен, саф һавада йөрергә кирәк.
....? Мин яшелчә ашарга яратам.
....? Дустым хастаханәдә ята, аның аягы авырта.
....? Рецепт алу өчен, әбием табибка барды.
....? Чыныгу өчен, мин көн саен физик күнегүләр ясыйм.

**15. Җөмләләрне дәвам итегез.** Продолжите предложения.

Иртә белән мин хастаханәгә ... .  Әбием табибтан рецепт ... . Дустымның башы ... . Бүген апамның кәефе юк,  ул ... . Мин дәрескә ...,  минем  кулым ... .

**16. Рәсемнәргә карагыз һәм сорауларга җавап бирегез.** Посмотрите на рисунки и ответьте на вопросы.



Сәлим нишли?



Әби кайда?



Сания нәрсә ашый?



Кешеләр кайда йөриләр?

**17. Укыгыз һәм сәламәт булу турында сөйләгез.** Прочитайте и расскажите о здоровом образе жизни.

Без сәламәт булырга тиеш. Сәламәт булу өчен, ит һәм сөт ризыклары, яшелчә һәм җиләк-җимеш  ашарга кирәк.  Кышын һәм җәен  көн саен саф һавада йөрү, йөгерү, чыныгу бик файдалы. Саф һавада йөрү өчен,  урманга бару бик әйбәт. Иртән физик күнегүләр ясарга кирәк. Иртәнге,  көндезге,  кичке ашны вакытында ашау бик мөһим. Сәламәтлек турында уйларга кирәк. Сәламәт кешеләр бәхетле булалар! Сәламәтлек – зур байлык ул.

**файдалы – полезно**

**вакытында – своевременно**

**мөһим – важно**

**байлык – богатство**

**18. Мәкальләрне укыгыз һәм истә калдырыгыз.** Прочитайте и запомните пословицы.
*Сәламәтлек – иң зур байлык ул.
(Здоровье – это самое большое богатство.)
*Сәламәт тәндә – сәламәт акыл.
(В здоровом теле – здоровый ум.)

**19. Дөрес әйтегез.** Скажите правильно.

д – [д] – дан, дус
дөрес, дәрес

т – [т] – тарих, тыныч
әти, тимер

**20. Дөрес языгыз.** Напишите правильно.

*Д д* ______________________________

*Т т* ______________________________

**21. Санны сүзләр белән языгыз.** Напишите число словами.
222 ____________

☑ **ҮЗ-ҮЗЕГЕЗНЕ ТИКШЕРЕГЕЗ!** ПРОВЕРЬТЕ СЕБЯ!

**1. Дөрес җавапны табыгыз.** Найдите правильный ответ.

Дустым табиб... бара.
1) -ка 2) -тә 3) -кә

Минем кулым бик авырт... .
1) -тым 2) -а 3) -ам

Дустым, Самат безгә кил... .
1) -дым 2) -сен 3) -дек

Бу ханым хастаханәгә бар... .
1) -дым 2) -а 3) -ырга

Бу әфәнде йөгерү өчен, стадион... бара.
1) -да 2) -га 3) -гә

Сәламәт булу өчен, спорт белән шыгыльлән.... кирәк.
1) -ергә 2) -ә 3) -ырга

Без  көн саен витаминнар ашый... .

1) -быз  2) -лар  3) -сыз

Сәламәтлег...  яхшы.

1) -ем  2) -сы  3) -се

2. **Дөрес тәрҗемәне табыгыз.** Найдите правильный перевод.

**авырта**

1) болеет  2) болит  3) гуляет

**шөгыльләнергә**

1) заниматься  2) думать  3) бегать

**файдалы**

1) полезный  2) польза  3) пользоваться

**саф һава**

свежий воздух  2) прогноз погоды  3) времена года

**йөгерү өчен**

1) для ходьбы  2) для того, чтобы бегать  3) для того, чтобы играть

**ашау**

1) пить  2) кушать  3) брать

**3. Коммуникатив биремнәрне языгыз.** Напишите коммуникативные задания.

1) Скажите, что у вас болит голова.
2) Спросите у прохожего, где находится больница.
3) Уточните у друга (подруги), болит ли у него (нее) нога.
4) Как скажете о том, что вы ходили к врачу?
5) Попросите у Азата чая.
6) Скажите Алсу, чтобы она купила лекарство.
7) Скажите о том, что Вам нужно выпить воды.
8) Посоветуйте другу (подруге) кушать овощи.
9) Скажите, что ваш друг занимается спортом.
10) Скажите, что каждый день нужно делать физические упражнения.



## СПОРТ УЕННАРЫ. СПОРТИВНЫЕ ИГРЫ

**1. Тыңлагыз һәм укыгыз.** Прослушайте и прочитайте.

**Сез кайсы спорт төре белән шөгыльләнәсез?** Каким видом спорта Вы занимаетесь?

Мин йөзү белән шөгыльләнәм.
Дустым футбол, баскетбол уйный.
Шамил бокс белән кызыксына.
Кышын без чаңгыда шуабыз.
Шакир тимераякта шуарга ярата.
Балалар чанада шуалар.
Элек мин теннис белән шөгыльләндем.

**йөзү – плавание**
**уйнарга – играть**
**чаңгы – лыжи**
**кызыксынырга – интересоваться**
**чана – санки**
**тимераяк – коньки**
**шуарга – кататься**

2. Диалогларны укыгыз һәм үрнәк буенча төзегез. Прочитайте диалоги и составьте по образцу.

— Гафу итегез, Сез кайсы спорт төре белән шөгыльләнәсез?
— Җиңел атлетика белән.
— Ничә ел шөгыльләнәсез?
— Сигез ел.
— Ярышларда катнашасызмы?
— Әйе, катнашам.

**җиңел атлетика – легкая атлетика**
**авыр атлетика – тяжелая атлетика**
**ярыш – соревнование**
**катнашырга – участвовать**

***

— Дустың спортчымы?
— Әйе. Ул йөзү белән шөгыльләнә.
— Ул көн саен бассейнга барамы?
— Юк, атнага өч тапкыр.

**спортчы – спортсмен**

***

— Син мәктәптә чаңгы шудыңмы?
— Юк, шумадым. Мин теннис уйнадым.
— Хәзер теннис уйныйсыңмы?
— Әйе, атнада өч тапкыр уйныйм.

**3. Рәсемнәргә карагыз һәм сорауларга җавап бирегез.** Посмотрите на рисунки и ответьте на вопросы.



Бу малай нәрсә белән шөгыльләнә?



Бу кыз нишли?



Азат кайсы спорт төре белән шөгыльләнә?



Бу абый нишли?

**4. Җөмләләрне тулыландырыгыз.** Дополните предложения.

Мин ... белән шөгыльләнәм. Мәктәптә мин тимераякта ... яраттым, хәзер бассейнда ... яратам. Кышын без апам белән чаңгыда ... . Җәен паркта ... яратабыз. Әтием һәм әнием дә спорт белән ... . Абыем элек теннис белән ..., хәзер ул авыр атлетика белән ... . Апам спорт мәктәбендә ..., ул җиңел атлетика белән ... . Без спорт ярышларын карарга ... .

**5. Җөмләләрне дәвам итегез.** Продолжите предложения.

Мин җиңел атлетика белән ... . Ул йөгерү белән ... . Без теннис белән ... . Алар чаңгы спорты белән ... . Дустым бокс ... . Апам фигуралы шуу белән ... . Абыем чана спорты белән ... .

**6. Укыгыз һәм истә калдырыгыз.** Прочитайте и запомните.

**Кайсы спорт төре?** Какой вид спорта?



**ат спорты – конный спорт**

Бу – ат спорты.



**милли көрәш – национальная борьба**

Бу – милли көрәш.



Бу – авыр атлетика.



**озынлыкка сикерү – прыжки в длину**

Бу – озынлыкка сикерү.



Бу – фигуралы шуу.

**7. Укыгыз һәм үрнәк буенча кышкы спорт төрләре турында әйтегез.** Прочитайте и скажите по образцу о зимних видах спорта.

Кышын күп кешеләр спорт белән шөгыльләнәләр. Кышын хоккей, чаңгы, тимераякта шуу, фигуралы шуу ярышлары була. Кышын чаңгыда йөрү бик файдалы. Кешеләр урманда, паркта рәхәтләнеп чаңгы шуалар, ял итәләр. Мин дә чаңгы шуарга яратам. Без дуслар белән тауга барабыз һәм анда чаңгы шуабыз. Миңа кышкы спорт төрләре бик ошый.

**рәхәтләнеп – с удовольствием**

**тау – гора**

**ошый – нравится**

**8. Җөмләләрне тулыландырыгыз.** Дополните предложения.

Кышын кешеләр ... шуалар. Балалар тауда ... шуалар. Дуслар ... карарга яраталар. Малайлар ... уйныйлар. Апам ... белән шөгыльләнә. Гаиләбездә ... шөгыльләнәләр.

**9. Сорауларга җавап бирегез.** Ответьте на вопросы.

Бу нинди спорт төре? Кышын кешеләр нинди спорт төрләре белән шөгыльләнәләр? Җәйге спорт төрләре ниндиләр? Бу кемнең чаңгысы? Дустың ничә ел тимераякта шуа? Сиңа кайсы спорт төре ошый? Бу кемнең чанасы? Абыең кайсы спорт төре белән шөгыльләнә? Сез ярышларда катнашасызмы? Яраткан спортчыгыз кем?

**10. Сораулар куегыз һәм укыгыз.** Поставьте вопросы и прочитайте.

...? Мин чаңгы спорты белән кызыксынам.

...? Дустым фигуралы шуу белән кызыксына.

...? Абыем милли көрәш белән шөгыльләнә.

...? Балалар чанада шуалар.

**11. Рәсемнәргә карагыз һәм сүзләрне истә калдырыгыз.** Посмотрите на рисунки и запомните слова.

**Бу нәрсә?** Что это?



Бу – туп.



Бу – кәшәкә.



Бу – көймә.

Бу кем? Кто это?



Бу – җанатар.



Бу – хөкемдар.



Бу – уенчы.

**12. Җөмләләрне дәвам итегез.** Продолжите предложения.

Чаңгы ярышында ...? Тимер аякта шуу ...? Бу туп – ...? Абыеңа кәшәкә ...? Көймәдә ничә ...? Сез көймәдә ...? Җанатарлар ....? Хөкемдар ...? Футбол кырында ...?

**13. Үрнәк буенча төрле спорт ярышлары турында әйтегез.** Скажите по образцу о разных спортивных соревнованиях.

*Үрнәк:* Бу – футбол ярышы. Футбол кырында ике команда бар. Беренче команда – «Рубин» командасы. Алар Казаннан. Икенче команда – «Зенит» командасы. Алар Мәскәүдән. Бу уен Казан стадионында була. Мин футбол карарга яратам.

**уен – игра**

**кыр – поле**

**14. Сорауларга җавап бирегез.** Ответьте на вопросы.

Бу нинди ярыш? Анда кемнәр катнаша?

Бу футбол уенымы? Бүген бу ничәнче уен? Уенда кемнәр катнаша?

Сез кайсы шәһәрдә яшисез? Сезнең шәһәрдә нинди спорт командалары бар?

Сезгә кайсы спорт командасы ошый?

**15. Дустыгызга шалтыратыгыз һәм ярышта җиңүе белән аны котлагыз.** Позвоните другу (подруге) и поздравьте его (её) с победой на соревнованиях.

— Алло, сәлам, Шәкүр!

— О-о-о, сәлам, Җәмилә!

— Шәкүр, чаңгы ярышында җиңүең белән!

— Рәхмәт, Җәмилә!

— Шәкүр, ярыш кызыклы булдымы?

— Әйе, күп шәһәрләрдән спортчылар катнашты. Син ярышны карадыңмы?

— Кызганычка каршы, юк. Мин өйдә булмадым.

— Ярышта безнең команда – беренче, Әлмәт командасы – икенче, Түбән Кама командасы өченче булды.

— Котлыйм сезне!

— Бик зур рәхмәт!

— Очрашканга кадәр!

**җиңү – победа**

**җиңәргә – победить**

**җиңелергә – быть побежденным**

**Истә калдырыгыз!** Запомните!

***Шөгыльләнергә*** (заниматься) / ***шөгыльләнмәскә*** (не заниматься) **фигыленең билгесез үткән заманда төрләнеше**

(спряжение глагола в прошедшем неопределённом времени)

**Мин шөгыльләнгәнмен / шөгыльләнмәгәнмен**

**Син шөгыльләнгәнсең / шөгыльләнмәгәнсең**

**Ул шөгыльләнгән / шөгыльләнмәгән**

**Без шөгыльләнгәнбез / шөгыльләнмәгәнбез**

**Сез шөгыльләнгәнсез / шөгыльләнмәгәнсез**

**Алар шөгыльләнгәннәр / шөгыльләнмәгәннәр**

**16. Яраткан спорт төрегез турында сөйләгез.** Расскажите о своём любимом виде спорта.
Мин .... белән кызыксынам. Мин .... белән ..... ел шөгыльләнәм. Элек әтием (әнием, апам, абыем) дә ... белән шөгыльләнгән.
.... – кызыклы спорт төре. Мин ... белән ... тапкыр шөгыльләнәм. Мин ... ярышларын телевизордан да, Үзәк стадионда да карарга яратам. ... спорты миңа бик ошый.

**яраткан – любимый**

**үзәк – центральный**

**17. Үрнәк буенча дустыгызның яраткан спорт төре турында сөйләгез.** Расскажите по образцу о любимом виде спорта вашего друга (подруги).
Дустымның яраткан спорт төре – чаңгыда шуу. Ул чаңгы спорты белән 10 ел кызыксына. Ул мәктәптә чаңгы ярышларында катнашкан, бүләкләр алган. Хәзер дә ул кышын атна саен 4 тапкыр паркта чаңгы шуа. Дустым биатлон, чаңгы эстафетасын карарга ярата.

**Истә калдырыгыз!** Запомните!
**-ган/-гән, -кан/-кән – билгесез үткән заман фигыль кушымчалары**
(аффиксы прошедшего неопределённого времени)
**Ул нишләгән? Ул барган, килгән, киткән, кайткан.**

**18. Үрнәк буенча диалоглар төзегез.** Составьте диалоги по образцу.
— Сез кайчан һәм кайда тугансыз?
— Мин 1986 нчы елның 5 нче июлендә Казанда туганмын.
***
— Дустың кайда туган?
— Ул Санкт-Петербургта туган.

**19. Шигырьне тыңлагыз һәм сәнгатьле итеп укыгыз.** Прослушайте и прочитайте выразительно стихотворение.

**Шуабыз**

Чанада да шуабыз,
Чаңгыда да шуабыз.
Тимераякта очабыз,
Чыжлап тора шома боз.

Кырларга да чыгабыз.
Кар-буран дип тормыйбыз.
Тауларга да барабыз,
Шуабыз да шуабыз.

*Нәҗип Мадьяров*

**20. Дөрес әйтегез.** Скажите правильно.

ж – [ж] – аждаһа
җ – [җ] – җылы, җиләк
ш – [ш] – Шакир, шуарга, шикәр, шәһәр
ч – [ч] – чын, чиста, чөнки

**21. Дөрес языгыз.** Напишите правильно.

*Ж ж* ____________________
*Ш ш* ____________________
*Җ җ* ____________________
*Ч ч* ____________________

**22. Санны сүзләр белән языгыз.** Напишите число словами.

333 ____________________

☑ **ҮЗ-ҮЗЕГЕЗНЕ ТИКШЕРЕГЕЗ!** ПРОВЕРЬТЕ СЕБЯ!

1. **Дөрес тәрҗемәне табыгыз.** Найдите правильный перевод.

**кыр**
1) дом 2) поле 3) гора

**чаңгы**
1) плавание 2) лыжи 3) сани

**уйнарга**
1) играть 2) игра 3) заниматься

**тимераяк**
1) лыжи 2) коньки 3) сани

**кызыксынырга**
1) играть 2) интересоваться 3) заниматься

**ошый**
1) нравится 2) конечно 3) катается

**2. Сүзләрне тиешле формада куегыз һәм языгыз.** Поставьте слова в нужной форме и запишите.

Кичә мин спорт ярышында (катнашырга) ... .

Дустым унике ел (йөгерергә) ... белән шөгыльләнгән.

Якшәмбе (көн) ... футбол ярышы булган.

Ярышка Мәскәү һәм Казан (шәһәр).... уенчылар килгән.

Кышкы спорт төрләре – хоккей, чана, чаңгы, тимераякта (шуарга) ... .

Кышын мин (бассейн) ... йөзәргә яратам.

Кышын балалар (тау) ... баралар.

**3. Коммуникатив биремнәрне языгыз.** Напишите коммуникативные задания.

1) Спросите друга (подругу), каким видом спорта он (она) занимается.
2) Уточните у прохожего, где находится стадион.
3) Скажите, какой вид спорта вам нравится.
4) Поинтересуйтесь у бабушки, занималась ли она фигурным катанием.
5) Позвоните другу и поздравьте его с победой в соревнованиях по биатлону.
6) Как скажете о том, что Вы любите плавать в бассейне?
7) Назовите любимый вид спорта вашего брата.
8) Скажите, что волейбол – очень интересная игра.
9) Как скажете о том, что вам нужен новый мяч?
10) Назовите вашу любимую спортивную команду.



## МИНЕМ БУШ ВАКЫТЫМ. МОЁ СВОБОДНОЕ ВРЕМЯ

**1. Тыңлагыз һәм укыгыз.** Прослушайте и прочитайте.

**Буш вакытта нишлисең?** Что делаешь в свободное время?

**Буш вакытта мин китап укыйм.**
**Буш вакытта мин кинога яки кафега барырга яратам.**
**Буш вакытта без дусларыбыз белән очрашабыз һәм аралашабыз.**
**Буш вакытта алар шахмат уйныйлар.**
**Буш вакытында ул газета укый, телевизор карый.**
**Буш вакытны файдалы үткәрергә кирәк.**
**Буш вакытым күп түгел, шуңа күрә мин кинога, кафега йөрмим.**

**буш вакыт – свободное время**

**яки – или**

**аралашырга – общаться**

**ял итәргә – отдыхать**

**2. Җөмләләрне тулыландырыгыз.** Дополните предложения.

Буш вакытта мин ... барам. Минем буш вакытым ... . Дустым буш вакытында ... аралашырга ярата. Буш вакытында ... барасың? Буш вакытта алар ... баралармы? Иртәгә буш вакытыгыз ...?

**3. Сорауларга җавап бирегез.** Ответьте на вопросы.

Син буш вакытыңны ничек үткәрәсең? Дусларың буш вакытларын кайда үткәрәләр? Буш вакытында нишләргә яратасың? Буш вакытында син кая барасың? Җәен нишлисең? Кышын тимераякта яки чаңгыда шуасыңмы? Синеңчә, буш вакытны ничек үткәрергә кирәк?

**4. Рәсемнәргә карагыз һәм сорауга җавап бирегез.** Посмотрите на рисунки и ответьте на вопрос.

Ул буш вакытында нишли?








**5. Диалогларны укыгыз һәм үрнәк буенча төзегез.** Прочитайте диалоги и составьте по образцу.

— Сәлам, Алсу!
— Сәлам, Алия!
— Син кичен бушмы?
— Әйе, бүген буш, ә иртәгә татар теле курсларына барам.
— Әйдә, татар театрына барабыз.
— Әйдә. Бик рәхәтләнеп.

***

— Сәлам, Ләйлә, хәлләр ничек?
— Рәхмәт, бик әйбәт.
— Син иртәгә нишлисең?
— Белмим әле. Иртәгә мин буш.
— Әйдә, музейга барабыз.
— Яхшы. Мин риза.

**мин риза – я согласен (на)**

***

— Гафу итегез, керергә ярыймы?

— Ярый, рәхим итегез.

— Рәхмәт. Мин – журналист, телевидениедән. Мин спорт клубы директорыннан интервью алырга телим.

— Гафу итегез. Хәзер директор буш түгел. Ун минут көтегез.

**көтәргә – ждать**

— Яхшы. Рәхмәт Сезгә.

**6. Җөмләләрне дәвам итегез.** Продолжите предложения.

Иртәгә дәресләр юк, мин ... . Ял көнне без ... . Буш вакытны файдалы ... . Гафу ит, бүген буш вакытым ... . Буш вакытта дустым спорт белән шөгыльләнергә ... .

**7. Шигырьне тыңлагыз һәм сәнгатьле итеп укыгыз.** Прослушайте и прочитайте выразительно стихотворение.

**Ял иттек**

Көнозын ял иттек без.
Шундый кызып киттек без:
Ялны иттек
Ятып та,
Утырып та,
Торып та.
Киерелдек –
Сузылдык,
Балык тоттык,
Кызындык,
Җиләк җыйдык,
Су кердек,
Ярдан суга
Сикердек...
Ял иттек без
Туйганчы,
Кичке тугыз
Булганчы,
Юк ла, унбер

Тулганчы,
Арыганчы –
Талганчы,
Тәмам хәлдән
Тайганчы.

*Роберт Миңнулин*

**8. Тыңлагыз һәм укыгыз.** Прослушайте и прочитайте.

**Мин буш вакытымны файдалы үткәрергә тырышам. Дусларым белән саф һавада йөрим, спорт белән шөгыльләнәм. Җәен күлдә су коенырга, футбол һәм волейбол уйнарга яратам, ә кышын чаңгыда һәм тимераякта шуам. Ял көннәрендә кинога, театрга, клубка бару да миңа бик ошый. Аннан мин яхшы кәеф белән кайтам.**

**ошый – нравится**

**тырышырга – стараться**

**саф һава – свежий воздух**

**кәеф – настроение**

**9. Укыгыз һәм тамга куегыз.** Прочитайте и поставьте значок.

**Сезгә нәрсә ошый?** Что Вам нравится?

| | | | |
|---|---|---|---|
| Кинога бару | ○ | Чаңгыда шуу | ○ |
| Теннис уйнау | ○ | Дуслар белән аралашу | ○ |
| Елгада йөзү | ○ | Саф һавада йөрү | ○ |
| Телевизор карау | ○ | Телефоннан сөйләшү | ○ |
| Музыка тыңлау | ○ | Китап уку | ○ |
| Телләр өйрәнү | ○ | Кунакка бару | ○ |

**10. Үзегезнең буш вакытыгыз турында сөйләгез.** Расскажите о своём свободном времени.

**11. Укыгыз һәм үрнәк буенча җөмләләр төзегез.** Прочитайте предложения и составьте по образцу.

Буш вакытымда мин дустым белән телефоннан сөйләшәм. Шимбә көнне дустым фитнес клубына бара. Якшәмбе саен алар велосипедта йөриләр. Буш вакытны күңелле үткәрәбез. Без өстәл теннисы белән кызыксынабыз.

**12. Җөмләләрне дәвам итегез.** Продолжите предложения.

Мин Казанда ... . Мин театр белән ... . Казанда театрлар ... . Буш вакытта без театрга ... . Анда дусларыбыз белән ... . Алар белән спектакль ... . Спектакльдән соң кафега ... һәм ... Казанда ел саен классик балет фестивале ... . Миңа бу фестиваль ... .

**13. Укыгыз һәм спорт комплекслары турында сөйләгез.** Прочитайте и расскажите о спортивных комплексах.

Без буш вакытта спорт ярышларын карарга яратабыз. Шәһәребездә «Бустан», «Москва», «Олимп» спорт комплекслары, Спорт сарае, «Татнефтьарена» спорт сарае, Баскетхолл, Үзәк стадион, Теннис академиясе бар.

Спорт комплексларында зур заллар, бассейннар, йөгерү юллары, тренажёрлар, сауналар бар.

Мин бигрәк тә хоккей, волейбол ярышларын карарга яратам.

**бигрәк тә – особенно**

**14. Сорауларга җавап бирегез.** Ответьте на вопросы.

Ничә кеше? ... . Ничәнче урын? ... . Сәгать ничәдә? ... . Ничәнче мартта? ... . Кая? ... . Кайсы спорт комплексында? ... . Кайсы команда?... .

**15. Диалогларны тулыландырыгыз.** Дополните диалоги.

— Сез кичә кая ...?
— Үзәк стадионга ... .
— Кем белән ... ?
— ... .
— Анда ... булды?
— ... .

— Сезнеңчә, вакытны файдалы үткәрү өчен, ...?
— Минемчә, ... .

**16. Сораулар куегыз һәм укыгыз.** Поставьте вопросы и прочитайте.

...? Буш вакытта мин бассейнга барам.
...? Дусларым буш вакытларында теннис белән шөгыльләнәләр.
...? Буш вакытымда мин детективлар укырга яратам.
...? Буш вакытында апам телевизор карарга ярата.
...? Дустымның буш вакыты бик аз.

**17. Тыңлагыз һәм укыгыз.** Прослушайте и прочитайте.

**Шәһәребездә музейлар бик күп. Без Муса Җәлил, Салих Сәйдәшев, Максим Горький музейларында булдык. Ял көнне без Тукай музеена бардык. Ул Тукай урамында урнашкан. Музейда Тукай турында китаплар, газеталар, журналлар күп. Монда Тукайның үз әйберләре дә бар. Музей безгә ошады.**

**үз – свой** **әйбер – вещь**

**18. Диалогларны укыгыз һәм үрнәк буенча төзегез.** Прочитайте диалоги и составьте по образцу.

— Исәнмесез!

— Хәерле көн!

— Хәлләр ничек?

— Рәхмәт, яхшы.

— Сез ял көннәрен ничек үткәрдегез?

— Бик яхшы. Шимбә көнне кибетләргә бардым, кичен дусларым безгә килде. Якшәмбе көнне без паркта, саф һавада йөрдек.

***

— Гафу итегез, Сез буш вакытыгызны ничек үткәрәсез?

— Мин вакытымны файдалы үткәрергә тырышам.

— Буш вакытта нишлисез?

— Саф һавада йөрим, газеталар укыйм, телевизор карыйм, музыка тыңлыйм.

**19. Сүзләрне кирәкле формада куегыз һәм укыгыз.** Поставьте слова в нужной форме и прочитайте.

Буш вакытта мин спорт ярышларын (карарга). (Шәһәр) спорт комплекслары күп. «Рубин» футбол командасы бик яхшы (уйнарга). Дустым гимнастика белән (кызыксынырга). Интернетта спорт турында күп (язарга). Универсиада авылы Казанның Идел буе (район) урнашкан. Без Президент кубогына чаңгы ярышында (катнашырга). Дустымның (тренер) – бик ярдәмчел кеше.

**20. Дөрес әйтегез.** Скажите правильно.

з – [з] – зирәк, зәңгәр, Зилә, Зөлфәт

с – [с] – сәләт, Сәлим, сары, соры

**21. Дөрес языгыз.** Напишите правильно.

З з ________________________________

С с ________________________________

**22. Санны сүзләр белән языгыз.** Напишите число словами.

444 ____________________

☑ **ҮЗ-ҮЗЕГЕЗНЕ ТИКШЕРЕГЕЗ!** ПРОВЕРЬТЕ СЕБЯ!

1. **Дөрес җавапны табыгыз.** Найдите правильный ответ.

Дустымның буш вакыт... юк.

1) -ы 2) -е 3) -ны

Бу кызлар театр... баралар.

1) -кә 2) -гә 3) -га

Бу студентлар спорт комплексы... баралар.

1) -ка 2) -нә 3) -на

Бу апа буш вакытында базар... йөри.

1) -га 2) -тән 3) -кә

Бу абый буш вакыт... телевизор карый.

1) -дә 2) -та 3) -да

Туристлар Тукай музее... булганнар.

1) -га 2) -на 3) -нда

Без ял көнне кино... барырбыз.

1) -гә 2) -да 3) -га

Мин буш вакытта кибет... барырга бик яратам.

1) -гә 2) -не 3) -кә

2. **Дөрес тәрҗемәне табыгыз.** Найдите правильный перевод.

**вакыт**

1) время 2) весна 3) выходной день

театрга

1) в театр 2) из театра 3) в театре

аралашырга

1) спать 2) общаться 3) играть

карарга

1) знать 2) смотреть 3) гулять

кәеф

1) игра 2) победа 3) настроение

**3. Коммуникатив биремнәрне языгыз.** Напишите коммуникативные задания.

1) Скажите, что вы любите играть в шахматы в свободное время.

2) Уточните у собеседника, в каких музеях он был.

3) Посоветуйте друзьям пойти в музей Салиха Сайдашева.

4) Поздравьте друга с победой в спортивном соревновании.

5) Спросите у прохожего, где находится Дворец спорта.

6) Как скажете о том, что надо проводить время с пользой?

7) Попросите у знакомого мяч.

8) Как Вы обратитесь к тренеру спортивной команды и спросите, сколько лет он работает с этой командой?

9) Как скажете о том, что очень полезно ездить на велосипеде?

10) Скажите, что у Вас очень мало свободного времени.




КИБЕТТӘ. В МАГАЗИНЕ

1. Тыңлагыз һәм укыгыз. Прослушайте и прочитайте.

Бу нинди кибет? Монда нәрсә саталар? Какой это магазин? Что здесь продают?

Бу – ипи кибете. Монда ипи, күмәч саталар.
Бу – ашамлыклар кибете. Монда ашамлыклар саталар.
Бу – киемнәр кибете. Монда киемнәр саталар.
Бу – яшелчә һәм җиләк-җимеш кибете.
Без монда җиләк-җимеш һәм яшелчә сатып алабыз.
Бу – ит бүлеге. Монда ит, казылык алабыз.
Бу – супермаркет. Монда бөтен нәрсә бар.

кибет – магазин
бүлек – отдел
ипи – хлеб
сатарга – продавать
күмәч – батон
сөт – молоко
сатып алырга – купить
чәй – чай
ашамлык – продукт
яшелчә – овощи
җиләк-җимеш – фрукты
ит – мясо
казылык – колбаса
кием – одежда

**2. Диалогны тыңлагыз һәм укыгыз.** Прослушайте диалог и прочитайте.

— Гафу итегез, якында ипи кибете бармы?
— Әйе, әлбәттә, бар. Әнә бу йортта ипи кибете урнашкан.
— Анда арыш ипие бармы?
— Анда ак һәм кара ипинең бик күп төрләре бар.

***

— Миңа бер кило алма үлчәгез әле.
— Яхшы. Хәзер үлчим.
— Ә сездә бәрәңге бармы?
— Бар. Килосы 7 сум.
— 3 кило бәрәңге бирегез әле.
— Яхшы.
— Рәхмәт.

**якында – поблизости**
**арыш ипие – ржаной хлеб**
**шикәр – сахар**
**алма – яблоко**
**бәрәңге – картофель**
**үлчәргә – взвешивать**
**түләргә – заплатить**
**сум – рубль**
**тиен – копейка**

**3. Җөмләләрне тулыландырыгыз.** Дополните предложения.

Без кибеттә ак икмәк, ярты литр сөт, шикәр һәм чәй … . Сатучы безгә ике кыяр, өч помидор һәм бер баш кәбестә … . Аннары без ит бүлегенә …, чөнки безгә … кирәк. Кибеттә без конфет та алдык, ә … . Кибеттә сөт бар, ә … . Бер литр сөт … сум. Бер кило ит … сум.

**Истә калдырыгыз!** Запомните!
**һәм** (и), **ә** (а), **ләкин** (но), **чөнки** (потому что), **яки** (или), **шуңа күрә** (поэтому) – **теркәгечләр** (союзы)

**4. Сорауларга җавап бирегез.** Ответьте на вопросы.

Сез нинди кибеткә бардыгыз? Кибеттә нәрсәләр алдыгыз? Дустыңа нәрсәләр алырга кирәк? Бу кибеттә казылык саталармы? Бер литр сөт ничә сум? Арыш ипие ничә сум? Син нинди ипи яратасың? Син ни өчен кибеткә бардың? Сез ничә сум түләдегез? Сатучы ничә кило конфет үлчәде?

**5. Рәсемнәргә карагыз һәм җавап бирегез.** Посмотрите на рисунки и ответьте на вопрос.

Бу нинди кибет?









**Истә калдырыгыз!** Запомните!

***Алырга*** (брать, взять, купить) / ***алмаска*** (не брать, не покупать) **фигыленең билгесез киләчәк заманда төрләнеше**

(спряжение глагола в будущем неопределённом времени)

| | |
|---|---|
| Мин алырмын / алмам | Без алырбыз / алмабыз |
| Син алырсың / алмассың | Сез алырсыз / алмассыз |
| Ул алыр / алмас | Алар алырлар / алмаслар |

**6. Диалогларны укыгыз һәм үрнәк буенча төзегез.** Прочитайте диалоги и составьте по образцу.

— Әйдә, иртәгә кибеткә барабыз!
— Нинди кибеткә?
— Китап кибетенә.
— Сиңа китап кирәкме?
— Әйе, анда яңа китаплар кайткан.
— Ярар. Барырбыз. Мин дә сүзлек алырмын.

— Исәнмесез! Сездә сыр бармы?
— Әйе, бар. Нинди сыр кирәк?
— Миңа «Пармезан» сыры кирәк.
— Рәхим итегез. Күпме үлчәргә?
— 200 грамм.
— Казылык та аласызмы?
— Юк, иртәгә алырмын.

**7. Җөмләләрне тулыландырыгыз.** Дополните предложения.

Җиләк-җимеш кибетендә мин ... алырмын. Китаплар кибетендә ул ... алыр. Бүген ... кибетенә ... барырбыз һәм ... алырбыз. Сез ... кайдан алырсыз? Сезнеңчә, алар бу кибеттә ... алырлармы? Кызлар ... кибеткә барырлар? Спорт киемнәре кибетендә син ... алырсыңмы? Сөт ризыклары бүлегендә мин ... алырмын, чөнки ... .

**8. Тыңлагыз һәм укыгыз.** Прослушайте и прочитайте.

Өебездән ерак түгел зур кибет урнашкан. Кичә кич белән без шул кибеткә кердек. Аның беренче катында аяк киемнәре саталар. Спорт товарлары бүлеге дә беренче катта.

Икенче катта өс киемнәре бүлеге бар. Анда күлмәкләр, кофталар, пальтолар, туннар сатып алырга мөмкин. Баш киемнәре бүлеге дә бар. Балалар киемнәре бүлегендә кешеләр матур киемнәр сатып алалар. Уенчыклар бүлеге дә, бизәнү әйберләре бүлеге дә икенче катта урнашкан.

Өченче катта көнкүреш техникасы бүлеге урнашкан. Анда суыткыч, кер юу машинасы, газ плитәсе, микродулкынлы мич, электр чәйнеге һәм башка әйберләр бар.

**аяк киеме – обувь**

**күлмәк – платье, рубашка**

**чалбар – брюки**

**өс киеме – верхняя одежда**

**тун – шуба**

**баш киеме – головной убор**

**балалар киеме – детская одежда**

**үлчәм – размер**

**уенчык – игрушка**

**бизәнү әйберләре – косметика**

**суыткыч – холодильник**

**кер юу машинасы – стиральная машина**

**чәйнек – чайник**

**9. Сорауларга җавап бирегез.** Ответьте на вопросы.

Хәзер сезгә нинди киемнәр сатып алырга кирәк? Дустыгыз өс киемнәре бүлегендә нәрсә сатып алыр? Сез бу баш киемен кайдан сатып алдыгыз? Дустыңа нинди төс ошый? Сез ничәнче үлчәм өс киеме киясез? Кышкы киемнәрне кайда сатып алырга мөмкин? Сез супермаркетларда нәрсәләр сатып аласыз? Яңа аяк киемен кайсы кибеттән сатып алырсыз? Гаиләгездә кем кибеткә йөрергә ярата?

**10. Сүзләрне кирәкле формада куегыз һәм укыгыз.** Поставьте слова в нужной форме и прочитайте.

Супермаркетта сез нәрсәләр (сатып алырга)? Сез кайсы кибеткә (барырга)? Дустыңа нинди чалбар (ошарга)? Алар сатучыдан нәрсә (сорарга)? Син кайсы кибеттә булырга (яратырга) һәм ни өчен?

**11. Җөмләләрне дәвам итегез.** Продолжите предложения.

Дустыңның туган көненә ... ? Әйтегез әле, кичә ул кайсы ... ? Гафу итегез, сез бу аяк киемен ... ? Кибеттә ул нәрсә ... ? Дустыгыз белән кайсы кибеткә ... ? Бүләк өчен ничә сум түләдегез?

**12. Укыгыз һәм китап кибете турында сөйләгез.** Прочитайте и расскажите о книжном магазине.

Казанда татар китабы кибете Бауман урамында урнашкан. Монда дәреслекләр, сүзлекләр, шигырь китаплары, романнар алырга мөмкин. Татар язучылары, артистлары турында китаплар да күп. Бу кибеттә балалар өчен дә бик матур китаплар бар.

Мин абыем кебек тарих турында китаплар укырга яратам, шуңа күрә Татарстан тарихы турында китаплар сатып алам.

**Истә калдырыгыз!** Запомните!

**Кебек, шикелле, сыман** (как) – **бәйлек** (послелог)

**әни кебек** – как мама, **синең шикелле** – как ты, **шар сыман** – как шар

**13. Дөрес әйтегез.** Скажите правильно.

А) Мин ипи кибете... барам. Анда бер кара ипи һәм бер ак ипи ал... . Кибет... тәмле тортлар да бар. Мин апам кебек «Татарстан» торты... бик яратам.

Ә) Кием... кибет... бик зур. Анда матур кием... бик күп. Кешеләр куртка..., күлмәк..., чалбар... сатып алалар.

**14. Диалогларны тулыландырыгыз.** Дополните диалоги.

— Дустым, бу матур кофтаны кайдан алдың?

— ... .

— Анда ташламалар юкмы?

— ... .

**ташлама – скидка**

***

— Бүген ашамлыклар кибетенә барабызмы?

— ... .

— Аннары китап кибетенә керербезме?

— ... .

***

— Яшелчәләр кибеттә арзанмы, базардамы?

— ... .

— Ә супермаркетта кыйбатмы?

— ... .

— Ә сөт ризыклары кайда арзанрак?

— ... .

**арзан – дешёвый**

**кыйбат – дорогой**

**15. Сораулар куегыз һәм укыгыз.** Поставьте вопросы и прочитайте.

... ? Казанда «Мега», «Тандем», «Метро» кебек зур кибетләр бар.

... ? Мин «Мега»дан матур күлмәк алдым.

... ? «Бәхетле» кибетендә ашамлыклар саталар.

... ? Миңа «Ашан» кибете ошый. Мин анда шимбә саен барам.

... ? «Кольцо» кибете 5 катлы.

... ? Мин автомобильләр кибетләрендә йөрергә яратам.

**16. Тыңлагыз һәм укыгыз.** Прослушайте и прочитайте.

**Миңа кышкы аяк киеме кирәк.**

**Дустым зур кибеттә уенчыклар бүлегендә сатучы булып эшли.**

**Энҗе бизәнү әйберләре бүлегендә зур ташламалар булуы турында әйтте.**

**Бу бүлектә ул кара куртка киеп карады.**

**Универмагта апам язгы аяк киеме сатып алган.**

**Миңа бу плащ бик килешә.**

**Яраткан төсем – кызыл төс.**

**киярга – надевать**

**килешә – подходит**

**киеп карарга – примерить**

**17. Рәсемнәргә карагыз һәм сорауларга җавап бирегез.** Посмотрите на рисунки и ответьте на вопросы.

Бу нинди бүлек?







Бу нәрсә?













**18. Диалогларны укыгыз һәм үрнәк буенча төзегез.** Прочитайте диалоги и составьте по образцу.

— Гафу итегез, сездә спорт киемнәре бармы?
— Әлбәттә, бар.
— Безгә хатын-кызлар өчен спорт киемнәре кирәк.
— Рәхим итегез, хатын-кызлар киемнәре бүлеге монда урнашкан.

***

— Сез ничәнче үлчәм өс киеме киясез?
— Мин 48 нче үлчәм киям.
— Кышкы киемнәрне кайда сатып алырга мөмкин?
— «Мега», «Тандем» кибетләреннән.
— Аяк киемнәрен күбрәк кайсы кибеттән сатып аласыз?
— «Идеал» кибетеннән алырга яратам.
— Сезгә нинди төсләр килешә?
— Миңа кара, кызыл төсләр килешә.
— Син бу бүлектә нәрсә киеп карадың?
— Мин көзге пальто киеп карадым.

**Истә калдырыгыз!** Запомните!
**-ыр/-ер, -ар/-әр, -р – билгесез киләчәк заман хикәя фигыль кушымчалары** (аффиксы будущего неопределенного времени):
Ул нишләр? Ал**ыр** – возьмёт, кил**ер** – придёт, яз**ар** – напишет, эч**әр** – будет пить, аш**ар** – будет кушать.

**19. Җөмләләрне тулыландырыгыз.** Дополните предложения.

Мин ... барырмын. Син ... алырсың. Ул ... киеп карар. Без ... керербез. Сез кафеда ... ашарсыз? Алар безгә ... килерләр? Бәйрәмдә сез ... котларсызмы? Дустыгызга ... бүләк итәрсез?

**20. Дөрес әйтегез.** Скажите правильно.

л – [л] – ләкин, ләкләк, лампа      м – [м] – малай, матур, машина

**21. Дөрес языгыз.** Напишите правильно.

*Л л* ______________________________

*М м* ______________________________

**22. Санны сүзләр белән языгыз.** Напишите число словами.

555 ____________________

☑ **ҮЗ-ҮЗЕГЕЗНЕ ТИКШЕРЕГЕЗ!** ПРОВЕРЬТЕ СЕБЯ!

1. **Дөрес җавапны табыгыз.** Найдите правильный ответ.

Дустым кибет... эшли.

1) -та 2) -тә 3) -дә

Бу кызлар супермаркет... баралар.

1) -кә 2) -гә 3) -ка

Бу студент китап кибете... бара.

1) -ка 2) -нә 3) -ына

Бу апа атна саен базар... йөри.

1) -га 2) -тән 3) -кә

Бу абый яшелчә базары... эшли.

1) -дә 2) -нда 3) -да

Туристлар «Мега»... барганнар.

1) -гә 2) -ка 3) -га

Без «Бәхетле»... барырбыз.

1) -гә 2) -да 3) -га

Мин кибет... барырга бик яратам.

1) -гә 2) -не 3) -кә

2. **Дөрес тәрҗемәне табыгыз.** Найдите правильный перевод.

**өс киеме**

1) обувь 2) верхняя одежда 3) головной убор

**сатучы**

1) продавец 2) бухгалтер 3) врач

**уенчык**

1) книга 2) хлеб 3) игрушка

**баш киеме**

1) обувь 2) одежда 3) головной убор

**сатып алырга**

1) купить 2) играть 3) читать

3. **Коммуникатив биремнәрне языгыз**. Напишите коммуникативные задания.

1) Скажите, что Вы работаете в книжном магазине.
2) Спросите у девушки, где находится магазин «Кольцо».
3) Поинтересуйтесь у бабушки, где она покупает молоко.
4) Как скажете о том, что ваша сестра работает в магазине игрушек?
5) Как скажете о том, что вы пойдёте в отдел спортивных товаров?
6) Скажите, что этот новый магазин – большой и красивый.
7) Как скажете о том, что вам нужна новая стиральная машина?
8) Спросите у сестры, купила ли она татарские книги.
9) Поинтересуйтесь у продавца, сколько стоит кирпич белого хлеба.
10) Скажите, что продуктовый магазин работает до 10 часов.



## ШӘҺӘРДӘ ҺӘМ АВЫЛДА. В ГОРОДЕ И В ДЕРЕВНЕ

1. Тыңлагыз һәм укыгыз. Прослушайте и прочитайте.

Минем туган шәһәрем – Казан. Ул – зур, борынгы шәһәр. Казан шәһәре Казансу елгасы буенда урнашкан. Казан – Татарстанның башкаласы.

Казанда истәлекле урыннар, мәйданнар, һәйкәлләр, бакчалар күп. Аларда шәһәр халкы һәм кунаклар рәхәтләнеп ял итә.

Туган шәһәремнең урамнары киң һәм чиста, ә йортлары биек һәм матур. Шәһәремдә театрлар, музейлар, китапханәләр, зур сәүдә һәм күңел ачу үзәкләре эшли.

Казан – тарихи шәһәр, шуңа күрә шәһәребезгә күп туристлар килә.

Шәһәребездә 2 миллионга якын кеше яши. Алар арасында татарлар, руслар, марилар, удмуртлар, чувашлар, үзбәкләр һәм башка милләтләр бар. Шәһәр халкы үзара дус һәм тату яши.

- истәлекле урын – памятное место
- мәйдан – площадь
- борынгы – древний
- сәүдә үзәге – торговый центр
- күңел ачу үзәге – развлекательный центр
- һәйкәл – памятник
- бакча – сад
- милләт – нация
- халык – народ
- тарихи – исторический

**киң – широкий** **чиста – чистый** **биек – высокий**

**2. Җөмләләрне тулыландырыгыз.** Дополните предложения.

Мин Мәскәү шәһәрендә ... . Россиядә иң зур шәһәрләр – ... . Татарстанның башкаласы – ... . Шәһәребезнең урамнары ... . Шәһәребездә тарихи урыннар ... . Казанда иң матур урыннар – ... . Шәһәр үзәгендә ... урнашкан. Казан университеты янында ... . Казансу елгасы буенда ... . Казан Кремле алдында ... .

**Истә калдырыгыз!** Запомните!

**Янында** (рядом), **алдында** (перед), **артында** (за), **буенда** (возле), **буйлап** (по), **арасында** (между, среди) – **бәйлек сүзләр** (послеложные слова).

Бәйлек сүзләр төрле килешләрдә кулланылалар (послеложные слова употребляются в разных падежах): **ал** – ***алдына, алдыннан, алдында.***

**3. Сорауларга җавап бирегез.** Ответьте на вопросы.

Сез кайсы шәһәрдә тугансыз? Шәһәрегез кайда урнашкан? Шәһәр янында нәрсәләр бар? Шәһәрегез буйлап йөрергә яратасыңмы? Шәһәрегездә музейлар, театрлар бармы? Дустың кайсы шәһәрдә яши? Аның шәһәре нинди? Сез кайсы шәһәрләрдә булдыгыз? Россия шәһәрләре арасында иң борынгылары нindиләр?

**4. Рәсемнәргә карагыз һәм сорауларга җавап бирегез.** Посмотрите на рисунки и ответьте на вопросы.

Бу нәрсә?













Туристлар кайсы шәһәрдә?









**5. Диалогны укыгыз һәм үрнәк буенча төзегез.** Прочитайте диалог и составьте по образцу.

— Исәнмесез!

— Хәерле көн!

— Гафу итегез, Сез Измирдәнме?

— Юк, мин Истамбулдан.

— Ә Казан Сезгә ошыймы?

— Бик ошый. Аеруча шәһәрнең үзәге, борынгы университет.

**Истамбул – Стамбул**

**6. Җөмләләрне дәвам итегез.** Продолжите предложения.

Татарстанда шәһәрләр күп: ... .

Алабуга шәһәрендә ... .

Түбән Кама шәһәрендә ... .

Яр Чаллыда ... .

Яшел Үзән шәһәре Казаннан ... .

Казан университеты шәһәребезнең ... .

Бу шәһәрдә төрле халыклар ... .

Татарстан шәһәрләре турында белү өчен, мин ... .

**Түбән Кама – Нижнекамск**

**Яшел Үзән – Зеленодольск**

**Чистай – Чистополь**

**Алабуга – Елабуга**

**Яр Чаллы – Набережные Челны**




7. **Укыгыз һәм сөйләгез.** Прочитайте и расскажите.

Алабуга шәһәре Татарстан Республикасының төньяк-көнчыгышында урнашкан. Алабугада бөек шәхесләр яшәгән. Монда Н.А.Дурова, И.И.Шишкин музейлары эшли. Танылган рәссам И.И.Шишкин монда туган һәм үзенең иң матур рәсемнәрен иҗат иткән. Шагыйрә Марина Цветаева бу шәһәрдә торган.

Алабугада «Шайтан каласы» («Чёртово городище») исемле археологик истәлек бар. Ул – борынгы Болгар культурасы истәлеге.

**көнчыгыш – восток**
**көнбатыш – запад**
**көньяк – юг**
**төньяк – север**
**көньяк-көнчыгыш – юго-восток**
**бөек – великий**
**шәхес – личность**
**иҗат итәргә – творить**

8. **Диалогларны тулыландырыгыз.** Дополните диалоги.

— Сез кайсы шәһәрдә ... ?
— Туган шәһәремнең исеме – ... .
— Ул кайда ... ?
— ... .

— Казан нинди ... ?
— Минемчә, ул ... .
— Анда нәрсәләр ... ?
— Анда ... .

9. **Укыгыз һәм үрнәк буенча әйтегез.** Прочитайте и скажите по образцу.

**Эшкә нәрсә белән барасың?** На чём ты едешь на работу?

Мин эшкә метро белән барам.

Апам университетка троллейбус белән бара.

Абыем бассейнга автобус белән бара.
Без бакчага машина белән барабыз.
Алар авылга поезд белән кайталар.
Европада күп кеше велосипед белән эшкә йөри.



**10. Сорауларга җавап бирегез.** Ответьте на вопросы.

Дустың кайсы авылда яши? Аның авылы нинди? Бу авылда күпме халык яши? Сез нинди авылларда булдыгыз? Сезгә кайсы авыл күбрәк ошады? Авылга нәрсә белән кайтасыз? Дустың авылны ярата мы? Шәһәрдән авылга кадәр ничә километр?



**11. Укыгыз һәм үрнәк буенча җөмләләр төзегез.** Прочитайте и составьте предложения по образцу.

Безгә Төмәнгә барырга кирәк. Мәскәү – илебезнең башкаласы. Шәһәребездә яңа йортлар күп. Хәзер шәһәребездә метро бар.

Татар авыллары бик матур. Мин бер татар авылында булдым. Бу авылның исеме – Ташлык. Ул Түбән Кама районында урнашкан.

**12. Җөмләләрне дәвам итегез.** Продолжите предложения.

Әбиебез авылда яши, шуңа күрә ... . Шәһәребез борынгы, шуңа күрә ... . Дустым авылда туган, ләкин ... . Җәен мин авылда яшим, чөнки ... . Ел саен без ... . Мин шәһәрне яратмыйм, ... .

**13. Укыгыз һәм авылыгыз турында сөйләгез.** Прочитайте и расскажите о своей деревне.

Татарстанда авыллар күп. Безнең авыл Чүпрәле районында урнашкан. Авылның исеме – Иске Шәйморза. Ул Чынлы елгасы буенда урнашкан. Авылда татарлар һәм чувашлар яши. Анда меңгә якын кеше яши. Авылда мәктәп, клуб, мәчет, хастаханә, кибетләр бар. Авылыбызның уртасында музей урнашкан. Монда авылыбыз турында тарихи истәлекләр, танылгын авылдашларыбызның портретлары, төрле китаплар бар. Музейга һәрвакыт кунаклар килә. Авылдашлар, мәктәп балалары, студентлар еш була. Без бу музейны бик яратабыз.

**14. Дөрес әйтегез.** Скажите правильно.

Кая? Татар авыл... . Кайчан? Җәй ае... . Кем белән? Апа ... . Ничек? Татар... . Нишләде? Ял ит... . Нишләячәк? Күңел ач... . Нишләр? Бар... . Нишләгән? Ту... . Нишли? Кызыксын...

**15. Укыгыз һәм үрнәк буенча дустыгызга хат языгыз.** Прочитайте и напишите письмо другу по образцу.

Исәнме, дустым Франциска!

Мин ярты ел инде Казанда яшим һәм университетта татар телен өйрәнәм. Дәресләрем атнага өч тапкыр була: дүшәмбе, чәршәмбе һәм җомга көннәрне. Дәрестә без укытучы белән татарча сөйләшәбез, диалоглар укыйбыз һәм сөйлибез, Татарстан турында текстлар укыйбыз. Дәресләр бик кызыклы. Татар телен өйрәнү миңа бик ошый. Казан да миңа бик ошый. Анда истәлекле урыннар күп. Мин музейларга, театрларга йөрим.

Синең хәлләрең ничек, Франциска? Дәресләрең күпме? Дусларың белән аралашасыңмы? Аларга миннән сәлам әйт. Хат яз. Көтәм.

Күп сәламнәр белән Гари.

**16. Сораулар куегыз һәм укыгыз.** Поставьте вопросы и прочитайте.

... ? Алар Кама буенда ял иткәннәр.
... ? Мин татар авылында булдым.
... ? Бу кыз татар авылында яши.
... ? Авылда дусларым күп.
... ? Авылыбызда зур мәктәп бар.
... ? Әнием авылның балалар бакчасында эшли.
... ? Экскурсовод безне авыл тарихы белән таныштырды.

**17. Шигырьдән өзекне сәнгатьле итеп укыгыз.** Прочитайте выразительно отрывок из стихотворения.

**Туган авыл**

Тау башына салынгандыр безнең авыл,
Бер чишмә бар, якын безнең авылга ул;
Авылыбызның ямен, суы тәмен беләм,
Шуңа күрә сөям җаным, тәнем белән...

*Габдулла Тукай*

**18. Рәсемнәргә карагыз һәм сорауга җавап бирегез.** Посмотрите на рисунки и ответьте на вопрос.

Бу нәрсә?



**19. Диалогны укыгыз һәм үрнәк буенча төзегез.** Прочитайте диалог и составьте по образцу.

— Сезнең авыл кайда урнашкан?
— Арча районында.
— Авылыгызның исеме ничек?
— Яңа Кырлай.
— Авылда Тукай музее бармы?
— Бар.

**Истә калдырыгыз!** Запомните!

**-са /-сә – шарт фигыль кушымчалары** (аффиксы условного наклонения)

Мин бар**сам** (если пойду)/барма**сам** (если не пойду) Без бар**сак**/барма**сак**
Син бар**саң**/барма**саң** Сез бар**сагыз**/барма**сагыз**
Ул бар**са**/барма**са** Алар бар**салар**/барма**салар**

**20. Җөмләләрне укыгыз һәм үрнәк буенча әйтегез.** Прочитайте предложения и составьте по образцу.

Авылга кайтсам, мин Сабан туена барырмын. Син килсәң, без яңа фильм карарбыз. Мәскәүдә булса, ул дуслары белән очрашыр. Без шәһәр үзәгенә барсак, сезгә дә әйтербез. Төркиягә барсагыз, истәлекле урыннарны карагыз. Авылда ял итсәләр, аларның сәламәтлеге яхшы булыр.

**21. Сынамышларны укыгыз һәм истә калдырыгыз.** Прочитайте приметы и запомните.

*Кыш кар күп булса, җәй яңгырлы булыр.

(Если зимой будет много снега, то лето будет дождливым.)

*Теш сызласа, һава бозылыр.

(Если зуб ноет, то погода испортится.)

**22. Дөрес әйтегез.** Скажите правильно.

н – [н] – мин, син, тун, кунак

ң – [ң] – мең, соң, яңа, яңгыр

р – [р] – рәхмәт, матур

**23. Дөрес языгыз.** Напишите правильно.

*Н н* ______________________________

*ң* ______________________________

*Р р* ______________________________

**24. Санны сүзләр белән языгыз.** Напишите число словами

**666** ____________________

☑ **ҮЗ-ҮЗЕГЕЗНЕ ТИКШЕРЕГЕЗ!** ПРОВЕРЬТЕ СЕБЯ!

**1. Дөрес җавапны табыгыз.** Найдите правильный ответ.

Дустым Казан шәһәре... бара.

1) -нә 2) -на 3) -гә

Җәен без авылда ял итә... .

1) -быз 2) -сың 3) -без

Бу ханым Берлин шәһәре... килгән.

1) -ка 2) -дән 3) -ннән

Бу әби авыл... яши.

1) -да 2) -дә 3) -га

Бу әфәнде... туган шәһәре – Измир.

1) -гә 2) -не 3) -нең

Автобус сәгать өч... китә.

1) -кә 2) -тә 3) -та

Без Париж... барабыз.

1) -гә 2) -га 3) -тән

Мин туган авылым... бик яратам.

1) -не 2) -ннән 3) -ны

2. **Дөрес тәрҗемәне табыгыз.** Найдите правильный перевод.

**кайтырга**

1) поехать 2) возвращаться 3) делать

**авылда**

1) из деревни 2) деревня 3) в деревне

**һәйкәл**

1) здание 2) площадь 3) памятник

**бакча**

1) сад 2) школа 3) дом культуры

**китәргә**

1) уехать 2) выйти 3) войти

**шәһәр**

1) город 2) село 3) поселок

**3. Коммуникатив биремнәрне языгыз.** Напишите коммуникативные задания.

1) Скажите, что вы любите свой город.
2) Спросите у прохожего, где находится музей Тукая.
3) Уточните у друга (подруги), на каких автобусах можно доехать до университета.
4) Как скажете о том, что ваш город находится на юге республики?
5) Спросите у подруги, где находится ее родной город.
6) Скажите, что вы любите отдыхать в деревне.
7) Как скажете о том, что Вам нужно поехать в Москву?
8) Скажите другу (подруге), что надо знать историю родного города.
9) Сообщите, что вы завтра пойдете в музей Мусы Джалиля.
10) Скажите, что вы должны рассказать монолог о Казани.



## КУНАКЛАР КАРШЫЛАУ. ТАТАР МИЛЛИ АШЛАРЫ.
## ВСТРЕЧА ГОСТЕЙ. ТАТАРСКИЕ НАЦИОНАЛЬНЫЕ БЛЮДА

**1. Тыңлагыз һәм укыгыз.** Прослушайте и прочитайте.

**кунакка барырга – ходить в гости**

**Без кунаклар чакырырга яратабыз.**
**Безгә кунаклар еш килә.**
**Кунакларны бәйрәмнәрдә, туган көннәрдә чакырабыз.**
**Кунакка туганнарыбыз, дусларыбыз килә.**
**Алар килүгә без тәмле ризыклар, татар ашлары пешерәбез.**

**чакырырга – приглашать**

**каршыларга – встречать**

**еш – часто** | **сирәк – редко** | **тәмле – вкусный**

**2. Җөмләләрне тулыландырыгыз.** Дополните предложения.

Туган көнемдә безгә ... . Бәйрәм көннәрендә мин дусларыма ... . Дустымның туган көненә мин ... . Бәйрәмгә кадәр алар ... . Бәйрәмнән соң син ... ? Кунакларыгыз кайчан ...? Сезне кем ...?

**3. Сораулар куегыз һәм укыгыз.** Поставьте вопросы и прочитайте.

...? Кичә безгә әбиебез кунакка килде.
...? Дустым апасына кунакка барган.

...? Алсуны дусты кунакка чакырган.
...? Безгә Мәскәүдән кунаклар килделәр.
...? Алар кунакларны вокзалда каршыладылар.

**4. Рәсемнәргә карагыз һәм сорауларга җавап бирегез.** Посмотрите на рисунки и ответьте на вопросы.

Кунаклар Казанга нәрсә белән киләләр?






Кунаклар сәгать ничәдә киләләр?






**Истә калдырыгыз!** Запомните!
**-са да/-сә дә – кире шарт фигыль кушымчалары**
(аффиксы уступительной модальности)

Мин бар**сам да** (если даже пойду)/барма**сам да** (если даже не пойду)
Син бар**саң да** / барма**саң да**
Ул бар**са да** / барма**са да**
Без бар**сак та** / барма**сак та**
Сез бар**сагыз да** / барма**сагыз да**
Алар бар**салар да** / барма**салар да**

**5. Диалогны укыгыз һәм үрнәк буенча төзегез.** Прочитайте диалог и составьте по образцу.
— Сез бүген кунаклар чакырдыгызмы?
— Әйе, чакырдык.
— Кемнәр килде?
— Дусларыбыз.
— Ә Мансур килдеме?
— Юк, чакырсак та килмәде, чөнки эштә булды.

**6. Җөмләләрне дәвам итегез.** Продолжите предложения.

Якшәмбе көнне өйдә булсам да, мин ... . Көн матур булса да, ... . Дусларыбыз чакырса да, без ... . Авылга кайтмасалар да, алар ... . Кунак чакырмасак та, ... . Бәйрәмгә бармасам да, мин ... . Кунакка барырга яратсам да, ... . Бәйрәм бетсә дә, ... .

**7. Шигырьне тыңлагыз һәм сәнгатьле итеп укыгыз.** Прослушайте и прочитайте выразительно стихотворение.

**Кунаклар**

Без әзерлибез табын,
Китереп бөтен ягын:
Уртага куйдык чәчәк,
Чәчәк янына – чәкчәк,
Бавырсак һәм кош теле.
Ризыклар төрле-төрле:
Сумса, бәлеш, өчпочмак,
Гөбәдия һәм коймак.
Һәркемгә чыгар өлеш:
Бар кыстыбый һәм бәлеш!
Җитешегез, кунаклар,
Кыстатмагыз, кунаклар!
Өйгә кайтып китәргә
Ашыкмагыз, кунаклар!

*Шәүкәт Галиев*

**8. Рәсемнәргә карагыз һәм сүзләрне истә калдырыгыз.** Посмотрите на рисунки и запомните слова.


Бу – чәкчәк.


Бу - өчпочмак.


Бу – гөбәдия.


Бу – кыстыбый.



Бу – вак бәлеш.



Бу – коймак.



Бу – кош теле.



Бу – пәрәмәч.

**9. Тыңлагыз һәм укыгыз.** Прослушайте и прочитайте.

**Ял көнне без кунаклар чакырдык, чөнки минем туган көнем булды. Бу көнне без апам белән табын әзерләдек, бик тәмле салатлар ясадык, бәлеш пешердек. Табынга яшелчәләр, ит һәм балык ризыклары, җиләк-җимеш, торт куйдык.**

**Кич белән дусларым кунакка килде. Алар мине туган көнем белән котладылар, бүләкләр бирделәр, матур сүзләр әйттеләр. Без аларны тәмле ризыклар белән сыйладык. Бәйрәм миңа да, дусларыма да бик ошады.**

**табын – праздничный стол**

**куярга – ставить**

**сыйларга – угощать**

**10. Сорауларга җавап бирегез.** Ответьте на вопросы.

Сезнең туган көнегез кайчан? Сез бу көнне ничек бәйрәм итәсез? Сезгә кемнәр кунакка килә? Кунаклар өчен нинди ризыклар пешерәсез? Өстәлгә нәрсәләр куясыз?

**11. Туган көнегезне бәйрәм итү турында сөйләгез.** Расскажите о праздновании своего дня рождения.

**12. Текстны тулыландырыгыз.** Дополните текст.

Яңа елда безне ... чакырдылар. Без кибеттә аларга ... алдык. Әбигә ... алдык, ә бабайга ... алдык, чөнки ул ... ярата. Аннары ... белән аларга бардык. Алар ... урамында яшиләр. Әби белән бабай безне ... . Без аларга ... бирдек һәм бәйрәм белән ... . Алар безне тәмле ... белән ... . Кунакта ... булды.

**Истә калдырыгыз!** Запомните!
**гына/генә, кына/кенә** (только), **ук/үк** (же), **әле** (ещё), **бит** (ведь), **инде** (уже), **да/дә, та/тә** (тоже), **-мы/-ме, -мыни/-мени** (ли) – **кисәкчәләр** (частицы).

**13. Укыгыз һәм үрнәк буенча җөмләләр төзегез.** Прочитайте и составьте предложения по образцу.

Алар безне генә кунакка чакырдылар. Алсу гына бәйрәмдә булмады. Булат кына бу бәйрәмне яратмый. Фәрит кенә безгә кунакка килде. Мин туганнарымны бәйрәм белән котладым инде, ә дустым котламаган әле. Ул бәйрәм турында белмәгән бит. Бәйрәм миңа да ошады.

**14. Сорауларга җавап бирегез.** Ответьте на вопросы.

Кайчан? ... . Кайсы бәйрәмдә? ... . Кемгә? ... . Кем белән? ... . Нәрсә турында? ... . Нишләр? ... . Нишләргә? ... . Кайсы көнне? ... . Сәгать ничәдә? ... . Ничәнче мартта? ... Кем өчен? ... .

**15. Диалогны тулыландырыгыз.** Дополните диалог.

— Сез кичә бәйрәмгә ... ?
— Әйе, ... .
— Бәйрәмдә ... булды?
— ... .

**16. Сораулар куегыз һәм укыгыз.** Поставьте вопросы и прочитайте.

...? Мин гөбәдия яратам.
...? Апам кыстыбый ярата.
...? Абыем коймак ярата.
...? Әби өчпочмак пешерә.
...? Без кибеттә чәкчәк алдык.
...? Бәлеш – кунак ашы.
...? Минемчә, иң тәмле татар ризыгы – гөбәдия.
...? Кунакларга татар ашлары бик ошады.

17. Тыңлагыз һәм укыгыз. Прослушайте и прочитайте.

**8 нче март – Әниләр бәйрәме. Мин бу бәйрәмне бик яратам. Бу көнне без әниемне бәйрәм белән котлыйбыз, табын әзерлибез. Табынга тәмле-тәмле ризыклар куябыз. Әнием гөбәдия пешерә. Чәй әзерлибез. Чәй янына кош теле, чәкчәк, лимон куябыз. Әнием чәйне сөт белән эчәргә ярата. Гаиләбез белән бик күңелле бәйрәм итәбез. Әниебез безгә рәхмәт әйтә.**

**18. Рәсемнәргә карагыз һәм сорауга җавап бирегез.** Посмотрите на рисунки и ответьте на вопрос.

Кем нәрсә ярата?



Алсу ... .



Әминә ... .



Азат ... .



Булат ... .



Самат ... .



Әнисә ... .

**19. Диалогларны укыгыз һәм үрнәк буенча төзегез.** Прочитайте диалоги и составьте по образцу.

— Хәерле көн, Марат!
— Хәерле көн, Илнур!
— Кая барасың?
— Бүген дустымның туган көне, аңа кунакка барам.

***

— Кунак чакыру өчен, нәрсәләр эшләргә кирәк?
— Минемчә, күп эшләр эшләргә кирәк.

— Сез шимбә кунакка бардыгызмы?
— Әйе, бардык.
— Кемнәргә бардыгыз?
— Әбигә.

**20. Җөмләләрне дәвам итегез.** Продолжите предложения.

Ай саен без ... . Бәйрәм табынына ... . Без кунакларны ... . Алар чәкчәк белән ... . Минемчә, иң тәмле ризык – ... .

**21. Мәкальләрне укыгыз һәм истә калдырыгыз.** Прочитайте пословицы и запомните.

*Кунак булсаң, тыйнак бул.

(Если ты гость, то будь скромен.)

*Өч көн кунак бул, өч көннән соң ерак бул.

(Три дня погости, через три дня будь далеко.)

**22. Дөрес әйтегез.** Скажите правильно.

х – [х] – хәлләр, халык h – [h] – һәйкәл, һава

**23. Дөрес языгыз.** Напишите правильно.

*Х х* ______________________________

*Һ һ* ______________________________

**24. Санны сүзләр белән языгыз.** Напишите число словами.

777 ____________________

☑ **ҮЗ-ҮЗЕГЕЗНЕ ТИКШЕРЕГЕЗ!** ПРОВЕРЬТЕ СЕБЯ!

1. **Дөрес җавапны табыгыз.** Найдите правильный ответ.

Дустым мине кунак... чакырды.

1) -тә 2) -та 3) -ка

Кунаклар.... каршыларга кирәк.

1) -да 2) -ны 3) -дан

Бу кыз безгә Америка... кунакка килгән.

1) -дән 2) -га 3) -дан

Апам өчпочмак пешер...

1) -ды 2) -де 3) -те

Чәкчәк бал... була.

1) -лы 2) -да 3) -ле

Без дусларыбызда бәйрәм... булдык.

1) -гә 2) -нән 3) -дә

Кунаклар... тәмле ризыклар белән сыйладык.

1) -га 2) -ны 3) -да

Өстәл... тәмле ризыклар бар.

1) -не 2) -дән 3) -дә

2. **Дөрес тәрҗемәне табыгыз.** Найдите правильный перевод.

**кунак**

1) гость 2) друг 3) ребенок

**бүләк**

1) отдел 2) подарок 3) книга

**коймак**

1) блины 2) пончики 3) коржик

**сыйларга**

1) приготовить 2) угощать 3) выбирать

**тәмле**

1) сладкий 2) вкусный 3) холодный

**каршыларга**

1) печь 2) встречать 3) провожать

**3. Коммуникатив биремнәрне языгыз.** Напишите коммуникативные задания.

1) Пригласите друзей на день рождения.
2) Поздравьте друга с днём рождения и пожелайте ему успехов.
3) Как скажете о том, что очень любите татарские блюда?
4) Спросите у прохожего, где находится Дом татарской кулинарии.
5) Скажите, что Вы были в Доме чая и Вам очень понравился чакчак.
6) Уточните у продавца, сколько стоит бялеш.
7) Поинтересуйтесь у собеседника, какие национальные блюда ему нравятся.
8) Посоветуйте друзьям купить в магазине «Бэхетле» хворост.
9) Позвоните другу (подруге) и уточните, во сколько часов прибывает поезд.
10) Скажите, что вы любите приглашать гостей.



ТАБИГАТЬТӘ. НА ПРИРОДЕ

1. Тыңлагыз һәм укыгыз. Прослушайте и прочитайте.

**Без табигатькә еш чыгабыз.**

**Без табигатьне яратабыз.**

**Табигатьне саклау – безнең бурычыбыз.**

**Без – табигать дуслары.**

**табигатьне саклау – охрана природы**

**бурыч – обязанность**

2. **Диалогларны укыгыз һәм үрнәк буенча төзегез.** Прочитайте диалоги и составьте по образцу.

— Сез табигатьтә еш буласызмы?
— Әйе.
— Кайда булырга яратасыз?
— Урманда, су буенда, тауларда.

— Сез кышын урманга барасызмы?
— Әлбәттә, барабыз.
— Урманда нәрсә эшлисез?
— Чаңгыда шуабыз, кышкы урманда йөрибез.

***

— Җәйге ялыгызны кайда үткәрәчәксез?
— Дачада булырбыз.
— Анда ничек ял итәчәксез?
— Су керәчәкбез, кояшта кызыначакбыз.

Истә калдырыгыз! Запомните!

*Барырга* (ходить) – фигыленең билгеле киләчәк заманда төрләнеше (спряжение глагола в будущем определённом времени).

**Мин барачакмын** (пойду)/**бармаячакмын** (не пойду) **Без барачакбыз/бармаячакбыз**

**Син барачаксың/бармаячаксың** **Сез барачаксыз/бармаячаксыз**

**Ул барачак/бармаячак** **Алар барачаклар/бармаячаклар**

**3. Җөмләләрне дәвам итегез.** Продолжите предложения.

Җәен без урманга барачакбыз, чөнки ... . Җәйге табигать бик матур, шуңа күрә ... . Җәйге каникулда мин авылда ял итәчәкмен, чөнки ... . Якшәмбе көнне без гаиләбез белән дачада ял итәчәкбез, анда ... . Августта дустым Кытайга барачак, чөнки ... .

**4. Сорауларга җавап бирегез.** Ответьте на вопросы.

Авылыгыз янында урман бармы? Сез урманга барачаксызмы? Сез анда нәрсә җыячаксыз? Җәен сез диңгезгә барачаксызмы? Дусларыгыз кайда ял итәчәкләр? Ял көнне син кая барачаксың? Сез җәйге ялда Төркиягә барачаксызмы? Кыш көне сез чаңгыда шуачаксызмы? Малайлар кыш көне хоккей уйнаячаклармы?

**җиләк – ягоды** **гөмбә – гриб** **җыярга – собирать**

**5. Җөмләләрне тулыландырыгыз.** Дополните предложения.

Без елга буена бармаячакбыз, чөнки ... . Алар дүшәмбе көнне ... кайтачаклар. Син дәрескә бармаячаксың, чөнки ... . Мин иртәгә ... китмәячәкмен. Сез авылга ... кайтачаксыз? Ул ... ял итәчәк? Алар ... нәрсә җыячаклар?

**6. Тыңлагыз һәм укыгыз.** Прослушайте и прочитайте.

**Кеше тормышы табигать белән бәйле. Табигать безгә ризык, кием бирә. Җирдән файдалы казылмалар алабыз. Урман безгә агач, җиләкләр, гөмбәләр бирә. Шуңа күрә табигатьне сакларга кирәк. Табигатьне саклау – безнең бурычыбыз.**

**Кешеләр ялларын табигатьтә үткәрергә яраталар. Урманнарга чыгалар, елга-күлләрдә су коеналар.**

